Шәһри КАЗАН

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 24 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
№ 9 (5187)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга
ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

Әхмәт МАЗҺАРОВ:

«МӘҢГЕ ЯШИМ ДИЕП ЭШЛӘРГӘ»

3,6 бит

«Шуны да син белмәгәч, ник киләсең мәчеткә?»

7 бит

10 бит

«Җитешсезлекләрне сәхнәдә сөйлисе килми»

КӨН АВАЗЫ

Яңа базарга бардыңмы?

Атна-ун көн элек Яшел Үзән юлы өстендә «Яңа Тура» технополисы эшли башлады. Колхоз һәм Вьетнам базарлары эшмәкәрләренең кайберләре шунда сату итә хәзер. Анда чиста, якты һәм җылы. «Яңа Тура»га барырга теләүчеләр өчен бушлай махсус автобуслар да йөри. Ә сез анда булырга өлгердегезме әле?

Нәҗибә САФИНА, шагыйрә:

– Барырга өлгермәдем шул. Вакыт әрәм итеп барырга да җыенмыйм. Мин базарларга бик сирәк барам. Күбесенчә кибеткә йөрим. «Яңа Тура»га түләүсез автобус йөри дип ишеттем. Алар бушка йөргәндә халык барыр анысы. Тик, миңа калса, аны гел дә бушлай итмәсләр. Түләүле була калса, халык йөрүдән туктардыр. Базарлар да, әйберләр дә күп хәзер, ә менә керемнәре начар. Шуңа да бу базарны халыкны җәлеп итү максатыннан ачканнардыр.

Рәшит САБИРОВ, нәфис сүз остасы:

– Әйбер кирәк булуга барачакмын. Базарның Яшел Үзән ягында ачылуына мин бик сөендем. Бердән, туган районым кешеләренә эш булачак. Икенчедән, базарны шәһәр үзәгеннән чыгару ул бөкеләрдән арынуның бер юлы. Азинодан Колхоз базарына төшү шул Яшел Үзән трассасына чыгу белән бер вакытны ала. Аның каравы машина кую урыны эзләп йөрисе булмас. Урамда сату итүчеләр өчен дә җайлы булгандыр. Өшеп ачык һавада басып торганчы, җылыда сату итү рәхәтрәк. Туңдыра дип аракы эчүчеләр дә бар иде араларында, алар хәзер җылыну чарасы эзләмәс.

Гөлфинә МАННАПОВА, газета укучы:

– Барып кайттым. Ошады. Чиста, уңайлы итеп эшләнгән. Халык азрак. Бер барып кайтырга гына кирәк. Аннары ияләшәчәкбез. Яңалыкны һәрвакыт куркып каршы алабыз инде ул.

«ШК» газетасының 29 гыйнвар — сишәмбе санына алхәбәр

Шамил Агеев: «Бер нәрсәне аңларга кирәк: безне берәү дә үз базарына болай гына чыгармаячак. Хәзер ничек кыссалар, алга таба да шулай кысачаклар. Моның өчен сәясәтне, конкурентлыкка сәләтне үзгәртеп корырга кирәк».

Айгөл ФӘХРЕТДИНОВА. «Россия әле һаман үзенең ВТОның тулы хокуклы әгъзасы булуына ышанып җитә алмый»

«Иң беренче артистның киеменә карыйм да, бусы эчке күлмәктән икән, дип, телевизорны сүндерәм дә куям. Җыры да, үзе дә кирәкми андыйларның. Күкрәк бит ул – хатын-кызның бала ашата торган әгъзасы, ул ябык булырга тиеш».

Фәүзия ЗАРИПОВА. «Тәре тага күрмәгез»

Атнага 3 тапкыр чыга торган газетаның индексы – 54126.

ҮГЕЗ ТҮГЕЛ ЧУРТ БУЛСЫН…

4 бит

КУЛЛАРЫҢНАН КУАН

8 бит

БАЙЛАР ДА ЕЛЫЙ

12 бит

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Безгә дә килегез

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Давоста эшлекле очрашулар һәм сөйләшүләр үткәрде.

Аның Европа реконструкция һәм үсеш банкы идарәче директоры Алан Пиллу белән очрашуында банкның республиканың инфраструктура үсеше белән бәйле проектларында катнашуын тагын да активлаштыру, сәнәгать, энергия саклау, торак-коммуналь хуҗалык, кече һәм урта бизнеска ярдәм проектларын гамәлгә ашыруда катнашу мәсьәләсе каралды. Рөстәм Миңнеханов Алан Пиллуны бизнес-миссия белән Казанга килергә чакырды, дип хәбәр итә Президентның матбугат хезмәте. ТР Президенты шулай ук Philips Electronics компаниясенең дәүләт органнары белән багланышлар буенча җитәкчесе Гарри Хендрикс, Dow Chemical компаниясенең Европадагы, Якын Көнчыгыш һәм Африкадагы башкаручы вице-президенты Хайнц Халлер белән очрашты.

Касса төбендә торасы юк

ИНТЕРНЕТ аша поездларга билет алучы пассажирлар саны елдан-ел арта бара.

2011 елда ерак араларга йөрүче поезд билетларын рәсмиләштергәндә 1 млн 67 мең кеше Интернет мөмкинлекләреннән файдаланган булса, узган ел аларның саны 1 млн 447 меңгә җиткән. Ягъни үсеш 35,6 процент тәшкил итә. Шуларның 991 меңе билетны «Россия тимер юллары» сайтына кереп рәсмиләштергән.

Җисеменә лаек исем булсын

УНИВЕРСИАДА ачылышы һәм ябылу тантаналары үткәрелергә тиешле 45 мең кешелек стадионга исем кушу буенча гаризалар кабул итү дәвам итә.

Бәйге башланганнан алып 600 дән артык хат килгән дә инде. Яңа стадионны укучылар Zilant-Arena, «Акзерубикс» һәм «Перемяч» дип атарга тели. Кемдер аны Корбан Бердыев («Рубин» ФК баш тренеры) исемендәге стадион буларак күрә, уннарча катнашучы Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев хөрмәтенә атау яклы. «Минтимер-Арена» яки «Тимер-Арена», мәсәлән. Милли колорит та читтә калмый, билгеле. Matur-Arena, «Түбәтәй», «Ак калфак», «Шүрәле», «Алга», «Сәлам», «Чәк-чәк», «Пәрәмәч-Арена»лар да бар исемнәр арасында. «Акзерубикс» дигәне бигрәк тә үзенчәлекле. «Ак Барс» (хоккей), «Зенит» (волейбол), «Рубин» (футбол), УНИКС (баскетбол) исемнәрен бергә кушканнан соң килеп чыккан иҗат җимеше анысы. 24 гыйнварга кадәр үз вариантыгызны тәкъдим итеп калыгыз. Аны «Бәйгегә» билгесе белән pr@tatar-inform.ru адресына җибәрергә кирәк. 25-30 гыйнвар көннәрендә беренче тур нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү булачак. Теләгән һәр кеше тәкъдим ителгән вариантларның берсе өчен тавыш бирә ала.

Базарда тагын янгын

ВЬЕТНАМ базарында берничә йөз миллион сумлык товар янып беткән.

Журналистлар урамындагы бу базарда зур янгын чыккан. Күпләп сату базарының 7 склады урнашкан ангарда килеп чыккан ут. Ишек-тәрәзәләр, көнкүреш техникасы, савыт-саба һәм автомобиль шиналары сакланган бирегә. Иртәнге 10нар тирәсендә килеп чыккан янгынны беренчеләрдән булып складта булган эшмәкәрләр үзләре күреп алганнар. Беренче янгын сүндерү машиналары килеп җиткәндә, ут инде товарның күп өлешен юк итеп өлгергән булган. Бу базарда әле күптән түгел генә янгын чыккан иде инде.

Өйрәткәндә өйрәнеп кал

ТАТАР теле, татарлар тарихы һәм ислам нигезләре буенча «Без – татарлар» дип исемләнгән кичке курслар уздырыла.

Аны Россия ислам университеты белән Бөтендөнья татар конгрессы оештыра. Дәресләр исә бушлай нигездә атна саен кичке сәгатьләрдә үткәрелә. Курслар тәмамлангач, сертификат бирелә. Кызыксындырган мәсьәләләр буенча оештыру җыелышы 1 февральдә кичке 18.00 сәгатьтә РИУның 319 нчы аудиториясендә була. Белешмәләр өчен тел.: 8-950-32-00-935, 8-927-422-17-51, 253-71 дип хәбәр итә «Татар-Информ» мәгълүмат агентлыгы.

ҖИР ҺӘМ КҮК

24-30 гыйнвар магнит кыры тыныч булачак.

«Икмәк базары» архитектура комплексы яңартыла

Казанда тарихи-мәдәни мирас һәйкәлләрен төзекләндерү чаралары дәвам итә. Профсоюзлар урамындагы 12 нче йорт та әлеге исемлеккә керә.

ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

«Икмәк базары сәүдә рәтләре» XVIII гасырда барлыкка килгән. Сәүдәгәр А.Меркулов 1874 елда сәүдә рәтләренең бер өлешенә торак йорт (Профсоюзлар ур., 12) төзеткән. Йортның дивары бизәкле. Иң сөенечлесе – йорт эчендәге ике борынгы мич сакланып калган. Аның берсе – Саксония фабрикасында, ә икенчесе Витебск шәһәрендә ясалган нәкыш белән бизәлгән.

– «Икмәк базары» архитектура комплексын төзекләндерү эшләренең барышы күпләр өчен үрнәк мисал. Шәһәр белән инвестор фикере тулысынча тәңгәл килә, – диде мэр Илсур Метшин эш сәфәре вакытында. «Osnova» компаниясе башлыгы Эдуард Колтун таныштырганча, комплексның бер бинасы инде төзекләндерелгән. Мичләрне төзекләндерүгә күп көч һәм тырышлык куелган. Әлеге мичләр яңартылган бинага урнашачак кибетнең зиннәтле бизәге булып торачаклар. Профсоюзлар урамындагы «Икмәк базары» комплексы 2002 елдан бирле шәхси милек санала. Эдуард Колтун аңлатканча, Казандагы тарихи биналарны Президент боерыгыннан соң киң колачлы төзекләндерүләр башлангач кына банклар кредитларны кулайрак процентларда бирергә ризалашкан. «Osnova» компаниясе тарихи-мәдәни мирас исемлегендәге башка биналарны да төзекләндерүгә алынырга ниятли.

Спортның техник төрләре буенча да Олимпиада кирәк

Автор фотосы

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шәхсән үзе дә 5 илдә автоузышларда спортчы буларак катнашты. Төрле елларда 3 нче, 2 нче һәм 1 нче урыннарны алуга иреште.

УНИВЕРСИАДА СУЛЫШЫ

Дамир БӘДРИЕВ

Бу мәгълүматны «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында узган матбугат конференциясендә хөкемдарларның республика коллегиясе рәисе Аркадий Дадаев әйтте. Ул Татарстан Президентының автомотоспорт үсешенә зур игътибар бирүен рәхмәт хисләре белән телгә алды. Биектау районында 1995 елда автодром төзелгәннән соң спортның бу төре тагын да җәнлана.

– Республикада 1996 елда автомотоспорт федерациясе оештырылды. Хәзер бездә, «КамАЗ-Мастер» командасын да санап, исемнәре танылган 76 автоузышчы бар, – диде Аркадий Дадаев. Узган ел Тимур Тимерҗанов ралли-кросс буенча Европа чемпионы исеменә лаек булган. Ашот Ервондян, Тимур Шиһабетдинов, Ирек Миннәхмәтов, Рәсүл Миңнеханов, Радик Миннәхмәтов, Сергей Белозеров, Леонид Панфилов һәм башка дистәләгән спортчылар автомотоспорт буенча Татарстан һәм Россия чемпионатларында лаеклы җиңүләр яулыйлар.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе урынбасары Радик Рамазанов сөйләгәнчә, республикада 62 картинг клубы эшли, аларда 3 меңнән артык бала шөгыльләнә. Казанда быелның июль аенда булачак Универсиада балалар һәм үсмерләр арасында спортны пропагандалауда ялкынлы шигарьгә әверелгән.

Республиканың автомотоспорт федерациясе башкаручы директоры Рафаэль Баһаветдинов хәбәр иткәнчә, быелгы сезон 26 гыйнварда «Усад» спорт комплексында ачыла. Бирегә «Национальный» классында Татарстан һәм Россия Кубокларының 1 нче этабы һәм «А-1600» төркемендә автоузышлар үткәреләчәк. Республиканың автомотоспорт федерациясе, инде спортның техник төрләре буенча да Олимпиада үткәрү турында уйланырга кирәк, дигән тәкъдим ясады.

ОЧТЫ-КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Аркадий ДАДАЕВ, хөкемдарларның республика коллегиясе рәисе:

— Петр I Европага «тәрәзә» ачса, Татарстан Европага «капка» ачты.

(«Татмедиа» агентлыгында автомотоспорт темасына узган матбугат конференциясендә әйткән сүзләре)

ЯШӘЕШ

ЗАГС документ сорамас

2015 елдан башлап Татарстан ЗАГСлары кешеләрдән берниндә документлар да сорамаячак. 210 нчы Федераль закон таләпләре нигезендә бу шулай каралган. 2015 елга кадәр ЗАГС органнарыннан алынган мәгълүматлар шәхси саклануданы документлар булып тора. Ә ТР ЗАГС органнары инде быелдан ук автоматлаштырылган ведомствоара үзара хезмәттәшлеккә күчәргә әзер икән. Вакыт, акча әрәм итеп документ ташып йөрүнең кирәге калмый. Шуңа да 2013 елның төп бурычы – ЗАГС ведомстводан тыш системасын кулланып, халыкның бердәй реестрын барлыкка китерү. Бу реестрны, ягъни исемлекне социаль әһәмияткә ия булган барлык төр мәгълүмат системаларында кулланып булачак. Мисалга, медицина, мәгариф, торак-коммуналь өлкәләрдә.

Сүз уңаеннан: Татарстанда узган елда никахны рәсмиләштерүгә гаризаларның 70 проценты электрон рәвештә бирелгән. Әмма шул ук вакытта аерылышу, исем алыштыру, гражданлык хәле актларына үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертү һәм башкалар буенча электрон гаризалар бик сирәк килгән.

«Хәтер сандыгы»нда җиңүчеләр!

КОНКУРС

Кешеләрне куандыру рәхәт, күңелле. Безнең өчен янәдән шундый матур мөмкинлек туды. Тарихи һәм мәдәни мирас елы уңаеннан үткәрелгән «Хәтер сандыгыннан» республика бәйгесенә нәтиҗәләр чыгарылды. «Шәһри Казан» газетасы инде менә берничә ел рәттән иганәчебез Роберт Бильсур улы Зәкиев белән берлектә төрледән-төрле бәйгеләр үткәрә. Безгә килгән хатлардан шул аңлашыла: кулына каләм алып хат юллаганчы, газета укучыларыбыз уйлана, хатирәләрен яңарта, нәтиҗәләр ясый.

Киләчәктә дә бу күркәм гадәтне дәвам итәргә, гамьле бәйгеләр үткәрергә язсын. Ә хәзер бик шатланып җиңүчеләребез белән таныштырабыз.

Ике беренче урын: Әдилә Хаҗиева, Казан шәһәре («Әнием күлмәкләрендә – әбием төсе»), Лидия Константинова, Мамадыш районы Усали авылы («Бу гармунның үз язмышы бар...») Бүләк – ЖК телевизорлар.

Ике икенче урын: Гөлсинә Животникова («Истәлеккә кызыл башлы сөлге»), Зәлия Зыятдинова («Халыкны ач үлемнән саклап калган базар»), Балтач районы Чепья авылы. Бүләк – фотоаппаратлар.

Ике өченче урын: Камилә Сафиуллина, Апас районы Болын-Балыкчы авылы («Кирпеч корылмалар – тарих истәлеге»), Рәсимә Шәрипова, Арча районы Кызылъяр авылы («Сандыкларда – язмыш, тарих...») Бүләк – электр иттарткычлары.

Кызыксындыру бүләге: Руфия Мифтахова, Балтач районы Арбор авылы («Чигешләрдә – әнием күңеле»).

Җиңүчеләребезне котлау тантанасы 4 февраль көнне 14 сәгатьтә «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә булачак. Адресыбыз: Чистай урамы, 5 нче йорт. Белешмәләр өчен телефон: 562-50-12.

Конкурста катнашкан барлык газета укучыларыбызга олы рәхмәтебезне җиткерәбез. Киләчәктә дә бергә булыйк!

Тизйөрешле трамвайлар апрельдә йөри башлый

СОРАУ-ҖАВАП

«Казанда тизйөрешле трамвайлар булачак, дип әйтелгән иде. Алар маршрутларга кайсы айдан чыгачаклар?

Мәдинә Хәсәнова, Казан».

Әлеге сорауга «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе генераль директоры Әсфән Галәвов җавап бирде:

– Студентларның халыкара җәйге Универсиадасына әзерлек кысаларында башкаланың электр транспорты паркы да яңартыла. Казанга 10 берәмлек гадәти һәм 20 берәмлек тизйөрешле трамвай кайтартылачак. Тизйөрешле трамвайлар «Казан» тимер юл вокзалы – «Кояшлы шәһәр» маршрутында хәрәкәтләнәчәк. Киләчәктә әлеге маршрут шәһәрне «божра»га алачак. Хәрәкәт «Казан» тимер юл вокзалы – Киров дамбасы – Лена урамы – Ямашев проспекты – Коньяк трасса – Җиңү проспекты – «Кояшлы шәһәр» – Борисково бистәсе – Вахитов мәйданы – Тимер юл вокзалы буенча капма-каршы юнәлешләрдә гамәлгә ашырылачак. Яңа трамвайлар маршрутларга апрель аеннан чыга башлаячак.

Роальд СӘГЪДИЕВ:

«Мин — татар»

«Шушындый кеше белән бер дәвердә туу, аның янәшәсендә утыру үзе генә дә зур дәрәҗә, – диде ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, юбиляр турында сүз башлап. – Бер татар гаиләсеннән ике бертуган академик, 2 Ленин премиясе лауреаты чыгу – үзе бер ачыш».

ЮБИЛЕЙ ИЛӘ

Гөлнара ГАЛӘВИЕВА

Роальд Зиннурович бүгенге Президент белән очрашуда да сүзне: «Мин татар», – дип башлады. Аңа Рөстәм Миңнеханов «ТР каршындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды. Татарның менә шундый уллары да бар!

Казанга үзенең 80 яшьлек юбилеен каршы алырга кайткан Россия һәм Татарстан Фәннәр академияләре академигы, бүгенгесе көндә Американың Мериленд штаты университеты галиме, физика-математика фәннәре докторы Роальд Зиннур улы Сәгъдиев иң әүвәл алтын медаль белән бүләкләнде. Ул – ТР Фәннәр академиясенең әлегә беренче медале.

1932 елда Мәскәүдә туган, дүрт елдан соң гаиләләре белән Казанга кайтып төпләнгән абыйлы-энеле Сәгъдиевләр (энесе Ренад Сәгъдиев – академик, химик) 19 мәктәптә белем алган. Аннан Роальд Зиннурович Мәскәү дәүләт университетын тәмамлаган. И.В.Курчатов исемендәге атом энергиясе институтында эшләгән, СССР Фәннәр академиясенең Себер төбәге физика институтында хезмәт куйган. Космик тикшеренүләр институтын җитәкләгән еллары да мәртәбәле Роальд Сәгъдиевнең. 1968 елда ул академик исемен ала, ике тапкыр Ленин премиясе лауреаты иясе була. 1990 елдан бирле татар академигы АКШта яши, президент Дуайт Эйзенхауэрның оныгы – Сьюзен Эйзенхауэр белән гаилә кора.

«Татар кызларын алып бетергәннәр, күрәсең, мин шуңа да Америка кызына өйләндем, – дип көлә Роальд әфәнде үзенең чит илдә корган никахы турында, уенын-чынын бергә кушып. Аннан сүзне фән тармагына бора: – Мин Татарстанда «дәүләт-фән» дигән проблема күрмим, Россиядә исә андый сәвал бар. Казан дәүләт университеты белән горурланам. Казанга кайтканда анда кереп чыгу җаен карыйм, Фәннәр академиясе дә шул маршрутка керә».

Рәсми чыгышында исә академик балачагы, фәнгә китергән юлы турында да шәрехләп узды. Буа районыннан килгән якташларына үз исемендәге премияләр дә тапшырды. Плазма физикасы буенча саллы хезмәтләр иясе үзенең Америкада да татарлар белән аралашып яшәве, кайда булса да, үзенең иң әүвәл татар кешесе булуын онытмавы турында да әйтеп узды. «65 яшьтә футболны ташларга туры килде. Компания юк чөнки, – диде ул, әңгәмәне шаянлык белән йомгаклап. – Оныкларым белән чаңгы гына шуабыз. Спорттан аерылырга ярамый».

«Мәңге яшим диеп эшләргә»

КҮҢЕЛ ТӘРӘЗӘСЕ

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Нур чәчеп торучы күзләр. Үз милләте өчен ут янып торган горур йөрәк. Үз эшенең түмән белеп, кадерен белеп эшләүче шәхес. Әле шуның өстенә үзенә карата соклану уята алырлык кеше дә икән ул **Әхмәт абый МАЗҺАРОВ**. «Нигез», «тамыр» дип сөйләшә алучы, үзәге туган ягы, атаана корган оя белән бәйләлеген югалтмаган кешедән дә бәһаләрәк тагын кем бар икән? Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, академик, техник фәннәр докторы, «ВНИИУС» (Идел буе углеводород чималы фәнни-тикшеренү институты) директоры Әхмәт Мазһарович Мазһаров белән шуңа да әңгәмә гамьле дә, мәгънәле дә булды. Академик шушы айда үзенең 70 яшьлек олы юбилеен билгеләп узды.

АХЫРЫ 6 НЧЫ БИТТӘ

АЙНУР ГАЛИМОВ

Медведев урлаган вакыт

Дмитрий Медведевның 4 еллык президентлык чорында кабул иткән кануннары арасында күпмедер дәрәҗәдә файдалылары да, бер кирәксезләре дә булды. Аның уңышсызлыкка тарыган указларының берсе – Россиянең бөтен территориясендә тулысынча җәйге вакытка күчү. 2011 елның февралендә гамәлгә кертелгәннән соң ук, ул үзгәреш тәнкыйть утына тотыла башлады. Кыш көне җәйге вакыт буенча яшәп карагач, ризасызлар саны тагын да артты һәм хәзер дә үскәннән-үсә.

Аның каравы, сыерлар бәхетле

Медведев бу карарын тормышка ашырырга җыенганда, тоташ җәйге вакытның байтак уңай якларын тапкан иде. Алар арасында электр энергиясенә экономия ясаудан алып сыерларның савымнары артуга кадәр аргументлар бар. Янәсе, сыер савучыларның вакыт алмашынган саен абзарга иртәрәк яки соңрак чыгулары сыерларның башларына берничек тә барып җитми, шуңа күрә алар сөтләрен әзерләп куярга җитешмиләр һәм азрак бирәләр. Хәзер, дөрестән дә, савым арткан үзе – фермерлар, бер сыердан көненә бер литрга күбрәк сөт савыла, дип шатланалар. Уттан файдалану да кимеде. Күпме экономия ясадык, дисезме? 0,3 процент чамасы, акчага күчергәндә, бу ел буена бер кеше 30 сумын янга калдыра дигәнне аңлата. Инде икенче кыш буе җәйге вакыт буенча яшәү тудырган уңайсызлыклар, проблемалар өеме янәшәсендә ул бер литр сөт, 30 сум акча һәм башка плюслар тузан бөртеге кадәр генә.

Халык хәзер, иртән торасың – караңгы, эштән кайтасың – караңгы, якты көнне күрми дә калабыз, дип зарлана. Кышның иң кыска көне – 21 декабрьдә кояш иртәнге унда гына чыкты. Өлкәннәр – эшкә, балалар мәктәпкә дөм караңгыда йөрергә тиеш дигәнне аңлата бу.

Кышкы вакытка күчми башлауның зыяны, беренче чиратта, үзен кеше сәламәтлегендә сиздертте. Кешенең организмы караңгыда яшәргә иләшмәгән, таң атканчы тору безнең биологик сәгатьләребезне җимерә, бу кеше гомерен 10-15 елга кыскарта, дип исәпләп чыгарган белгечләр. Һәр иртә организм яңарсын һәм яшәү өчен мөһим процесслар эшкә керешсен өчен, кеше кояш белән бергә торырга, күзләрен ачуга, кояш нурларын күрергә тиеш икән. Сизенгәнсездер: хәзер кичтән йоклап китүе, иртән йокыдан айнуы бик кыенлашты, бу, аннан тыш тагын эштә гел йокы басу, организмның арыган булуы, ял соравы, аппетит бозылу – барысы да кышын сәгать телләрен артка күчермәүнең күңелсез нәтиҗәләре. Ул инсульт һәм инфарктлар очракларын, табибларга йөрүләр, ашыгыч ярдәм чакыртулар санын да нык арттырган. Караңгы вакытның озынаюы урамнарда тәртипсезләнеп йөрүләр, сугышулар, җинаятьләр, юл һәлакәтләре исәбенең үсүенә дә китергән.

Утка экономия ясау мәсьәләсе дә ике яклы булып чыккан. Эш шунда: йортлардагы күпчелек счетчиклар кышкы вакытка күчүгә программалаштырылган, шуңа күрә, дөрестән дә, азмы-күпме экономия ясау өчен кешеләргә 300-1500 сум түләп, ул аппаратларны көйләргә яки алмаштырырга кирәк.

Хаталар өстендә эш

Вакытның падишаһы булырга маташу теләгеннән Медведев хәзер үзе дә шат түгел икән инде. Хөкүмәт рәисе футбол карау кыенлашканына зарлана. Дөрестән дә, туры эфирда Европа, дөнья чемпионатларын карау өчен безгә яңа вакыт буенча төн уртасында да уяу булырга кирәк. Татарстанда быел Универсиада, киләсе елда Россиядә Олимпиада буласын исенә төшереп, Медведев хәзер үзе дә ялгышын таныган.

Хәзер хөкүмәттә хаталар өстендә эш бара. 20 декабрьдә уздырылган пресс-конференция вакытында Путин бу проблема халык фикерен исәпкә алу юлы белән хәл ителәчәген белдергән иде. Дума хөкүмәткә элеккеге кебек җәйге һәм кышкы вакытлар буенча яшәүгә кайту турында мөрәҗәгать әзерләп тапшырган инде. Шулардан чыгып, быелдан октябрьнең соңгы якшәмбесендә сәгать телләрен бер сәгатькә артка күчерү гадәтен кире кайтарылар дигән төпле ышаныч бар.

Шул ук вакытта, тулысынча кышкы вакытка гына да күчәргә була дигән сүзләр йөри. Галимнәр ул вакытның кешенең биологик сәгатьләре белән максималь якын туры килгәнен дәлилләп маташалар.

НИХӘЛ, АВЫЛ?

Ашлама алып калыгыз!

Россия Бөтендөнья сәүдә оешмасына кергәч, минераль ашламаларның бәяләре үзгәрәчәк. Шуңа күрә ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Минсагыйрь Нуртдинов Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ашлама сатып алырга, аны алу өчен кредит рәсмиләштерүне тизләтергә тәкъдим итте.

Киңәшмәдә язгы-кыр эшләренә дә аерым тукталдылар. Минсагыйрь Нуртдинов әйтүе буенча, 505 чәчү комплексын ремонтларга кирәк.

Кукмарада кошчылык фабрикасы ачылды

Кукмарада район эшмәкәрләре, яшелчә складын алып, аны төзекләндереп, инкубатор-кошчылык фабрикасы ясаганнар. Узган атнада фабриканың ачылыш тантанасы булып узды. Биредә Удмуртия Республикасыннан чебиләр алып кайтырга җыеналар. Соңыннан аларны өч айга кадәр үстереп сатачаклар. Киләчәктә исә биредә 50 мең баш чеби чыгара торган инкубатор да буласы, дип хәбәр итә Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, район чыганагына сылтама күрсәтеп.

Яңа төрле слива ашыйбыз?

«Синеокая» дип аталырга тиешле яңа сорт сливаның уңыш бирүчәнлеге бүгенге көндә үстерелә торганнарына караганда 15 процентка күбрәк. Аның җимешләре дә эрерәк, салкынга каршы торучанлыгы да көчле, витаминнарга да бик бай. Әлегә Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты аны сортларны сыный торган дәүләт комиссиясенә тапшырган. Яңа сорт слива җимеш бирә торган культураларны селекцияләү лабораториясе мөдире, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Геннадий Осиповныкы. «Синеокая» сливасы республикабызның климат шартларында эшләп чыгарылган, ә үзебездә үскән җимешләр организмыбыз өчен аеруча да файдалы, дип хәбәр итә институт галимнәре «Татар-Информ»га.

Сәхифәне Чулпан НӘҖИПОВА әзерләде

Үгез түгел чурт булсын...

Алдагы атнада авыл хуҗалыгында уртага салып, гөж килерлек ике тема булды. Беренчесе – «Вамин-Татарстан» җәмгыятенә башкарма директор итеп күп еллар «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының җитәкчесе булып эшләгән Марат Муратовның билгеләнүе.

Фото бизгә өчен бирелә

МӨНӘСӘБӘТ

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Бу яңалыкны халык «журналист сыер савачак» дип шаярту белән кабул итсә дә, Марат Муратов өчен авыл хуҗалыгы алай ук ят түгел, Түбән Кама районы җитәкчесе урынбасары буларак ул нәкъ менә шушы тармакка җаваплы булган. Марат Муратовны җитәкче буларак билгеле торган сыйфатларның берсе – аның нык сүзле, кырыс булуы. Холкының шушы ягын күз алдында тотып булса кирәк, берәүләр: «Сыер сөт бирсен өчен, иң элек башыннан сыйпарга кирәк», – дисәләр, икенчеләр исә яңа җитәкче килеп: «Сыердан сөт бирәсеңме, итме?» – дип сораса, савым артырга тиеш дип елмаялар. Болар, әлбәттә, шаярту гына. Марат Муратовның «кырыслыгы максатчанлыгыннан» дип бәялик тә яхшыны өмет итик. Яңа җитәкче алдына куелган бурычларның да иң мөһиме – савымны арттырудан да бигрәк, банк-кредиторлар (Сбербанк, «АК БАРС» Банк, Татфондбанк, Россельхозбанк һәм «Зенит») белән эшне җайлау һәм «Казан» компаниясенә күчерелгән җиде сөтмай комбинатының язмышын хәл итү. Ә «Вамин-Татарстан» җәмгыятенең киләчәгеннән республикабызның бик күп авылларының, анда эшләүче, яшәүче кешеләрнең язмышы бәйле.

Гәп куерган темаларның икенчесе «Кызыл Шәрык Агро» җәмгыяте, тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, компаниянең җитәкчесе Айрат Хәйруллинга кагылышлы иде. «Кызыл Шәрык Агро» җәмгыяте белән халык шул тикләм мавыкты ки, «Вамин-Татарстан» мөһимрәк булса да, аның мәшәкатьләре бөтенләй икенче планга ук күчте. «Кызыл Шәрык Агро» очрагында да сүз сөттән башланды. Соңгы вакытта җәмгыять сөтне киметүдә гаепләнеп, күп тапкырлар тәнкыйть утында тотылган иде. Айрат Хәйруллин шушы нисбәттән халык белән интернет аша әңгәмә корып җибәрде. Халыктан килгән фикерләрнең елмайта торганнары да, уйландыра торганнары да бар. Айрат Хәйруллинга һәр җөмләсен саннар белән дәлилләп, исбатлау хас. Аның фикеренчә, һәр өлкәдә төгәллек булырга тиеш, уйлап чыгарылган саннар, күрсәткечләрне югары итеп күрсәтүнең икенче тискәре ягы да бар. Мәсәлән, «алты имиле сыерлар» сөтенең үз кыйммәтен арттыра. Моңа төшенү алай авыр түгелдер. Мәсәлән, чынбарлыкта сыер йөз, ашатылган азык хисаптагы җитмеш баш сыерга гына бүленә. Шулай итеп сөтнең үз кыйммәте дә арта. Саннар белән дус булсаң, әлбәттә, яхшы, ләкин бар кеше дә санап утыра алмый, кемдер эшләргә дә тиеш. Әлеге урында ирексездән шаян сүз искә төшә: «Үгез түгел чурт булсын, балаларга сөт булсын», – дигәнме әле бер абзый. Шуның кебек иң мөһиме: авылларыбыз яшәсен иде дә, Тукай әйтмешли, кырларыбызга җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында яусын иде. Ул вакытта санарга да күпкә җиңелрәк.

ТУЙ КИЛӘ ДИП, ТУН ТЕГЕЛӘ

Бер җитәкче үзенең кул астындагы кешеләрен ал-ял бирми ел буе эшләтә торгач, үзе дә тәмам арыган ди. Һәм, юллама алып, ял йортына киткән. Ул киткәч, бөтен авыл халкы эш ташлап, кырылып ял итә. «Күр әле син аны, Ходайның рәхмәте, бер юлламага (!) бөтен авыл ял итте бит», – ди икән арада берсе. Әлеге мәзәкне Азнакай районы Тукай исемендәге ҖЧҖдә узган республика семинары барышында хуҗалык җитәкчесе Габделәхәт Рафыйков юкка гына искә төшермәгәндер. Әмма ни хикмәт, быел хәтта үзе юллама белән Мисырга ял итәргә китеп баргач та, авыл халкына, терлекчеләргә, терлек фермаларын төзекләндерүдә эшләүчеләргә әллә ни тугарылырга, үзе әйтмешли, «кышкы йокыга талырга» туры килми.

АЛДЫНГЫ ТӘҖРИБӘ

Расиха ФӘИЗОВА,
Азнакай

Хуҗалык базасында ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов катнашында терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерүгә сакчыл караш булдыруга багышланган зона семинары үткәрү тәгаенләнсен дә йоклап та ят икән. Кыш уртасы дип тормыйлар, ныклап торып эшкә тотыналар. Хуҗалык белән соңгы ун елда җитәкчелек иткән кеше буларак, Габделәхәт Гатуф улы Рафыйковка кайда ни кирәген кешедән сорыйсы түгел. Тик кайчак, иске яңаны саклый дигән сылтау белән, йә акча җәлләп, йә вакыт булмаудан, моңа кадәр кул җитмәгән эшләр дә җитәрлек шул. Бигрәк тә терлек фермаларын төзекләндерүдә эшләүче дүрт бригадада эш кырмыска оясындагы кебек кайный. Булганны сипләүнең генә әллә ни кыенлыгы да юк кебек – берсе дә терәүгә калмаган. Электәннән тотрыклы эшләүче авыл буларак, ферма торaклары төзек, утарлары ныклы, тимер коймалар белән әйләндереп алынган, терлекләрнең баш саны да даими үсештә бара Чубар Абдулда. Бүгенге көндә хуҗалыкта 1150 баш мөгезле эре терлек, 50 баш ат, 250 баш сарык асрала. Туй килә дип, тун тегелгән ди, ди бит. Монда да нәкъ шул. Биналар яңабаштан чистартыла, агартыла, буясы буяла, ферма эчендәге юлларга пычкы чүбе түшәлә. Яңа объектлар салынмаса да, бөтен матди-техник база ныгытыла, алмаш профилакторийларның читлекләре тулысынча алыштырыла, ягъни 15әр яшь бозау сыярлык 45 читлек булдырыла. 100 баш бозауны салкын алым белән үстерү өчен ике төрле ысул белән ясалган читлекләрен генә күр. Беришесе эчтә тактадан бүленгән булса, икенчеләре тышта булып, такта читлекләрнең ян-яклары, түбәләре кипләнгән салам белән төреп ышыкланган. Аяк астына башта 10 см лап пычкы чүбе, аның өстенә 15 см лап вакланган салам түшәлгән. 10-15 еллар элек республика хуҗалыкларында очраштырган мондый тәҗрибә соңгы елларда онытыла да башлаган булган икән.

– Миңа калса, һәр хуҗа сакчыл булырга тырыша. Бу юнәлештә безнең дә башкалар белән уртаклашырлык тәҗрибәбез дә бар. Әйтик, кыллы лампочкалар бөтенләе белән диодлыларга алыштырылды. Электрдан утын ягуга көйләнгән җылыту системасының да нәтиҗәсе озак көттермәс. 27-30 процентка экономия бирер дип уйлыйбыз. Гомуми көтүдән «брак»ка чыгарылган савым сыерларны герефорд токымлы үгез белән каплатып, ит токымлы бозаулар алдык. Бу безнең өчен генә түгел, республика күләмендәге яңалык булып тора. Бозаулар тәүлегенә 1кг-1кг 200 грамм үсеш бирәләр. Азыкны ферментлаштыру цехы үзе генә дә ни тора. Ягъни терлекнең кан составын шикәргә баету, тулыландыру, икенче төрле әйтсәк, фәннең фермага үз аягы белән килеп җитүе дигән сүз бу, – ди Габделәхәт Рафыйков.

Белгечләргә аерым бүлмәләр, ягъни маллар табибы, ясалма орлыкландыру технигы, терлекчеләрнең ял бүлмәсе, ферма мөдире, киенү-чишенү бүлмәләре һәм дә җыелыш залы җиһазландырылу, гомумән, фермага бәйләнеше булмаган авыл кешесендә дә кызыксыну уята. Республика семинарыннан соң озак көттерми, гомер буе терлекчелектә эшләгән 50ләп пенсионерны яңалыклар белән таныштырырга дип, фермага кунакка дәшә Г.Рафыйков. Фермадан кайтып, бергәләп ашханә табыны янына утыргач та, сүз гел шул хакта була. Гомерләрен терлекчелеккә багышлаган апа-абыйларның ихлас рәхмәтләрен ишетү һәм: «Мондый рәхәт безгә эләкмәде. Киредән фермага чыгып эшлиселәр килеп китте», – диюләре үзе генә дә эшләгән эшкә олы бәһа булып тора түгелме? Бүген инде Тукай исемендәге хуҗалыктагы яңалыкларны өйрәнергә дип, күрше-тирә авыллар гына түгел, башка районнардан да киләләр. Димәк, республика семинарындагы сүз урыннарга да кайтып ирешкән.

Ә ул семинар үткән көнне авыл халкы әле кайта-кайта сөйләр. Бу кадәр машинаның Чубар Абдулда Сабантуйда да җыелганы булмагандыр. 403 кеше яшәгән авыл 300дән артык кунакны кабул итте ул көнне.

Журналист җавап эзли

Республикабызда «Яңа Тура» технополисы төзелеп, әкренләп Казандагы базарларның барысы шунда күчеп бетәчәге турындагы сүзләр инде күптәннән йөри иде. Бу технополисның бөтен Идел буенда күмәртәләп һәм берәмләп сатып алу, ял итү һәм күңел ачу үзәгенә әвереләчәге турында да сөйләделәр. Әлеге проектта эшмәкәрлек, сәнәгать, белем бирү – барысы бергә үрелергә тиеш. Бу яңалыклар һәр кешенең колак очына гына булса да эләгеп калгандыр. «Яңа Тура»ның үз эченә 16 рәтне сыйдырган беренче павильоны инде эшли дә башлады. Әмма бу турыда белүчеләр генә сирәк икән әле.

Казан базарлары «ЯҢА ТУРА»га күченде

Чулпан НӘҖИПОВА

Туп-туры «Яңа Тура»га — бушлай автобусларда

«Яңа Тура» («Яңа Тура» атамасы яңа торак, ныгытма, шәһәр дигәнне аңлата) турында кемнән генә кызыксынып карасам да, үземә үк: «Кайда урнашкан соң ул?», «Ачылмагандыр әле ул!», «Белмим, ишеткәнем юк», «Анда нәрсә сатыла?» – кебек сорауларны яудыра башладылар. Боларның барысына да ачыклык кертер өчен, «Яңа Тура» технополисының үзенә барып кайтырга булдым. Өстәвенә анда берничә тукталыштан бушлай автобуслар йөри башлады. Үзем исә «Кәҗә бистәсе» метро станциясе янындагы тукталыштан барырга уйладым. Анда шулай ук Тимер юл вокзалыннан, Компрессорлар заводыннан, ЦУМ һәм Урман аръягы бистәсеннән дә һәр сәгать саен автобуслар йөреп тора икән. «Яңа Тура» технополисына автобуслар сәгать иртәнге 8-дән йөри башлый. Автобусның шоферы әйтүе буенча, Казанга иң соңгы маршрут кичке дүрттә кайтып китә. Шулай итеп, ун туларга ун минутлар тирәсендә «Кәҗә бистәсе» метро станциясе янына чыктым. Минем шикелле, тукталышның кайсысыннан китә икән инде бу автобус дип (ул тирәдә автобуслар берничә җирдә туктый бит), баш ватып йөрмәгез, туп-туры Макдоналдс урнашкан яктагысына килегез. Монда бер кеше дә юк бит дип тә аптырамагыз. Чыннан да, әлегә технополиска йөрүчеләр әллә ни күп түгел. Автобус килгәнен озак көтәргә туры килмәде үзе, сәгать унда ул кузгалып та китте. Бу маршрут турында кешенең белеп бетермәгәнлеге сизелеп тора, «Яңа Тура»га ярымбуш зур кызыл автобус белән киттек: салонда нибары 12 кеше иде.

Технополис Яшел Үзәнгә бара торган юлда урнашкан. Үз машинаң белән барсаң да, кайда икән инде ул дип баш ватасы юк, чөнки юл буенча әллә ничә юл күрсәткече очрый. Бару вакытына килгәндә, якынча 40-45 минут чамасы килеп чыкты. Бүгенге көндә Казанның бер башыннан икенчесенә бара башласаң, берничә сәгать вакыт кирәк булуын исәпләсәң, моны бик озак дип әйтеп тә булмый.

Менә нинди ул зур базар!

Автобустан чыгуга ук, игътибарымны тирә-яктагы зур-зур павильоннар җәлеп итте: кайсы инде төзелеп бетеп килә, кайсында әле төзелеш эшләренең нәкъ урак өсте. Булачак технополисның мәйданы бик зур буласы, бөтен тирәлекне күзләп бетереп тә булмый. Без, Казаннан алып монда кадәр үк базарга дип килгән 12 кеше, тизрәк яңа гына эшли башлаган бердәнбер павильонга ашыктык.

Җылы, якты, яңа, чиста, биек һәм иркен (!) рәтләрне күрү, әлбәттә, сөендерде. Гадәти базарларга килеп керүгә үк, этеш-төртеш башлана, аннан тизрәк чыгып китү теләге туа иде, бигрәк тә шимбә-ял көннәрендә. Ә монда рәхәтләнеп, ашыкмыйча йөр дә йөр, сайла, киеп кара. Рәтләр бөтенләй буп-буш булыр дип уйлаган идем, әмма бик күп булмаса да, һәрберсендә диярлек халык бар: кем кием сайлый, кем карап кына йөри. Товарның ассортиментына килгәндә, монда әлегә, нигездә, кием-салым гына сатыла: оекбашлардан башлап, курткаларга кадәр, шулай ук кичке күлмәкләр, юбка-блузкалар, урын-җир әйберләре, спорт киемнәре һ.б.ны алырга була. Электр товарлары сата торган бүлек тә бар. Берәмләп алучылар өчен бәяләр шул ук Колхоз базарындагы кебек тоелды. Ә менә күмәртәләп алучылар өчен, кагыйдә буларак, бәяләр бермә-бер түбән. Әйтик, бер кичке күлмәк өчен 1000 сум түлисе була, ә берничәне алсаң, 650 сумга төшә.

Әлеге павильонда ук тамак ялгап алыр өчен бик зур булмаган кафе да ачып куйганнар, шулай ук рәтләр буенча да тәгәрмәчле арбаларда чәй, каһвә, камыр әйберләре сатып йөриләр. Тагын гаҗәпләндергәне шул булды: монда хәтта чәчтарашханә ачарга да өлгергәннәр. Биредә инде эш бара. Килгән-килгән, ике куянның койрыгын берьюлы тотарга – чәчеңә прическа ясатып яки кистереп тә кайтырга мөмкин. Бәясенә килгәндә, хатын-кызларга 250-300 сум булса, ир-атларның чәчен 200 сумга да кисәләр. Технополиста күп җирдә проблемага әверелгән бәдрәфләр турында да онытмаганнар. Кыскасы, биредә сатып алыр өчен дип, арбалар белән килүчеләр күбрәк иде. Колхоз базарыннан күченеп килгән сатучы

> ***«Яңа Тура» базарлар җыелган урын гына булып калмыйча, монда игътибар гаилә һәм дуслар белән рәхәтләнеп ял итүгә дә юнәлдереләчәк. Киләчәктә биредә туристик проектлар оештыру да, велосипедта йөрү өчен юллар ясау, скейт-парк, кунакханәләр, рестораннар ачу һ.б. күздә тотыла***

Мария апа әйтүенчә, халык Казанның үзеннән дә, республикабызның төрле районнарыннан да, мәсәлән, Чистай, Яшел Үзән, Әлмәт һ.б. килә. Киров, Чуашстан, Мари Эл һ.б. чит өлкәләрдән дә күп йөриләр ди.

«Яңа Тура» инде иртәнге 6да ук үз ишекләрен ача (сатучылар исә 5тә үк килеп җитә): бу вакытка барлык сатучылар да эш урынында булырга тиеш. Мария апа таныштырганча, инде эш сәгате башлануга ук, күмәртәләп алырга дип килгән халык кереп тула. Базар сәгать көндезге икегә кадәр эшли, әмма кайчан китәсен сатучы үзе карый, кемдер сәгать бердә үк китеп барса, кемдер, киресенчә, өчкә кадәр дә тоткарланырга мөмкин, дип аңлатты Мария апа. Дүшәмбе исә базарның ял көне санала.

«Яңа Тура» ачылгач, Казандагы барлык базарларның да әкренләп бергә күчеп бетәчәген әйткәннәр иде инде, чөнки быелдан гамәлгә кергән 271 нче номерлы федераль закон буенча, хәзер ачык мәйданнарда сату тыела. Моның иң беренче чиратта Колхоз һәм Вьетнам базары арендаторларына кагылачагы да фаразланды. Шулай булып чыкты да, бүгенге көндә «Яңа Тура»да сату итүчеләрнең күпчелеген Колхоз базарыннан килгән сатучылар алып тора, шулай ук Вьетнам базарыннан күченүчеләр дә бар икән. Кайсы гына сатучыдан сорашсам да, барысы да мондагы шартлардан канәгать. «Иң мөһиме – җылы», – диләр гомер буе урамда өшеп-туңып торырга мәҗбүр булган апалар. Ә монда барысы да уңайлы һәм җиңелчә генә киенеп, рәхәтләнеп эшли. Сатучыларның күбесенең эшли башлаганнарына әле ун көн, ике атна гына. Гыйнвар-февраль айларында әлегә арендага да түләтмиләр. Киләчәктә аның күпме булачагы да төгәл билгеле түгел. Әмма ничек кенә булса да, алга таба бар да монда сату итәргә җыена.

«Яңа Тура»га халык йөрерме?

«Яңа Тура»да сату-алу өчен бөтен шартлар да бар, барам дисәң, автобусы да бушлай. Тик шулай да гади сатып алучы, шул ук олы яшьтәге әби-апаларыбыз анда кадәр барып йөрерләрме икән – менә монысы шик тудыра. Әлегә күпчелек, кызыксынып, беренче тапкыр килә. Әмма бүгенге көндә Казанның һәр урамында зур-зур кибетләр, сәүдә үзәкләре ачылып кына тора һәм шул ук базардагы әйберне теләсә кайсы кибеттән дә алып була бит. Мәшәкате дә азрак, вакытка да экономия. Дөрес, монысы берәмләп ала торган гади сатып алучылар турында. Ә менә күмәртәләп алучылар һәм сатучыларның үзләре өчен барлык уңайлыклар да булдырылган.

«Яңа Тура»да сату ике төрле оештырылган: берәмләп тә, күмәртәләп тә алырга мөмкин. Әмма сатып алучылар арасында, товарны махсус күпләп алучыларга «Яңа Тура» менә дигән урындыр, мөгаен. Аның максаты да шул бит: бөтен Идел буенда иң эре күмәртәләп һәм берәмләп сатып алу үзәгенә әйләнү.

Аннары «Яңа Тура»ның әле бер генә павильоны ачылуын да исәпкә алырга кирәктер. Ә бит аның планы киңкырлы. Ул базарлар җыелган урын гына булып калмыйча, монда игътибар гаилә һәм дуслар белән рәхәтләнеп ял итүгә дә юнәлдереләчәк. Киләчәктә биредә туристик проектлар оештыру да, велосипедта йөрү өчен юллар ясау, скейт-парк, кунакханәләр, рестораннар ачу һ.б. күздә тотыла. Технополисның тагын бер аерым проекты – агрокомплекс булдыру. Бу Татарстан фермерларына үз продукцияләрен югары технологияләр ярдәмендә эшкәртергә, сакларга һ.б. зур мөмкинлек бирәчәк. (Дөрес, Казанның үзендә дә Татарстанда җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен агросәнәгать комплексы ачылырга тора.) «Яңа Тура» технополисын төзүнең максаты – базарда сату итүне заманча тәртипкә салу, сатучылар һәм сатып алучылар өчен уңайлы шартлар тудыру; шул ук вакытта Казан базарлары тирәләрендә барлыкка килә торган бөкеләр проблемасын хәл итү, шәһәрне тәртипкә китерү, чистарту һ.б.

Болар «Яңа Тура»да барлыкка киләчәк проектларның, ул хәл итәсе проблемаларның бер өлеше генә. Киләчәктә аның нинди булачагын вакыт күрсәтер... Әлегә биредә уңайлы шартларда барлык гаиләгә кием-салым җыеп кайтырга була.

...Барлык рәтләрне әйләнеп чыгып, янә автобус янына тезелештек. Кемдер ничек буш кул белән килсә, шулай ук чыкты, арада пакет-пакет әйбер алучылар да бар иде үзе. Белмим, ничек шулай туры килгәндер, әмма кире Казанга кайтканда да, алдан сөйләшеп куелган кебек, «Кәҗә бистә»сенә кайта торган автобуста тагын нәкъ 12 кеше иде...

Ә сезгә «Яңа Тура»да ошыймы?

Надежда Морозова, Урман аръягы, сатып алучы:

– Безнең өчен «Яңа Тура» бик тә уңайлы, чөнки безгә ул якын. Бөтен кирәкле киемнәрне, вак-төякне җыеп кайтырга була, кыйммәт тә түгел. Алга таба шунда иялəшеп китәрбез дип уйлыйм. Әмма кайбер автобусларның бездә туктамавы гына борчый.

Лилия Сәлимова, Казан, сатып алучы:

– Зарланырлык түгел үзе. Бүген беренче генә тапкыр килүем. Иркен, тынычлап йөрергә була. Әмма атна саен йөри торган җир түгел инде бу. Монда кадәр килеп йөргәнче, мин шул ук әйберне Казаннан алам. Бүген куртка алырга дип килгән идем, күпме генә карап йөрсәм дә, үземә ошаганын таба алмадым. Бер көнем бушка үтте дигән сүз. Тагын килерменме-юкмы монда – әйтә дә алмыйм. Яңа павильоннар ачылгач, бәлки, тагын бер килеп чыгармын әле. Әмма бер әйбер өчен генә монда йөрергә җыенмыйм.

«МӘҢГЕ ЯШИМ ДИЕП ЭШЛӘРГӘ»

БАШЫ 3 НЧЕ БИТТӘ

Апрельдән — яланаяк

– Әхмәт Мазһарович, Балтач районы Сасна авылында калган балачак хатирәләре төшкә керердәй үк татлы булмагандыр. Әмма ул Сезнең телгә дә «нигез» төшенчәсе белән кереп калган. Шул нигез – авылны әйтүем, бөтен әйбәт, бөтен булган кеше шуннан чыга бугай?

Минем балачак сугыштан соңгы авыр елларга инде ул, сеңлем. Газ юк, электр юк, ашау ягы ташка үлчим. Әтием мулла булгач, бик зур салымнар салып, каһәрләп кенә торалар. Карават юк, урындык юк, кием-салым сәләмә, әмма өй тулы – китап. Әтием Мазһар да гел күз алдымда китап укып утыра... Мулла дигәч тә, сүз дини китаплар турында гына бармый. География, астрономия, физика, математика, тарих китаплары ул. Минем әтием дә, бабам да Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган кешеләр. Әти татарча, фарсыча, русча, гарәпчә, төрекчә белә, французча да сукалый иде. Мәдрәсәдә тел укыту көчле булган, шул исәптән Коръәнне дә. Бүгенге яшьләр кебек дискотекалар, боулинг, фитнес дип җенләнмәгән алар. Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаганнар шуңа да бар яктан белемле булган. Бабам Мирхафиз Пенза өлкәсенең Качкыру авылыннан килеп укыган, аннан Саснада төпләнеп калган.

Минем балачак йөз процент хәерчелек белән сурәтләнә. Әти-әни эшкә киткәндә берешәр телем ипи тоттырып китә. Без – балалар, бүре көтүе кебек, көне буе үз карамагыбызда. Апрельдән бирле яланаяк. Ундүрт яшькә өлкән Мөхәммәт абыем, Сальма апам белән үстем. Мөхәммәт абыем минем физика-математика укытучысы булды. Кичләрен керосин лампасының музыкасы астында без икәүләп мәсьәлә чишеп утыра идек. Ул заманнар таякка эшләү диган нәрсә белән кереп калса да, мәктәптә укыту көчле иде. Укысаң, кеше була идең.

– Уку-укыту белән беррәттән ул чор үзенең рухи яктан төзегрәк җәмгыять, рухи кыйммәтләр кадере белән дә истә калгандыр әле?

– Ул вакытта кешенең киләчәккә өмете көчле иде. Без патриот ил булдык. Әле мин мәктәптә укыган чакларымны гына искә төшерәм – мәктәп директоры безне айга бер тапкыр җыеп, Сталин карарларын укый иде. Ил үсеш кичерә – бәяләр төшә, кибетләр байый, төзелеш бара, завод-фабрикалар калкып чыга. Кая анда безнең чорда дәүләткә ышанмау, күңел төшенкелеге дигән нәрсә булсын. Без бит сугыштан соңгы егерме елда атом бомбасы, спутниклар ясаган ил!

– Шул күтәрелеш Сезне Казан вузына китерде?

– Минем максат – уку иде. Шәһәргә китү акча артыннан куудан түгел, гаиләдән килгән максат – белем алуга кайтып кала. Балтачтан чыккан бездән олырак Татарстан галимнәре КХТИның дары ясый торган факультетын тәмамлаган иде. Стипендия анда 100 сумга артыграк. Алар артыннан мин дә шул факультетка – 25 баллдан 24 балл җыеп, укырга кердем.

– Ул вакытта шәһәр белеме белән авылныкы аерылмаган инде алайса?

– Шәһәр балалары институтта беренче-икенче елда гына шомарак. Аннан авыл малайлары узып китә аларны. Без бит эшләп чыныккан. Иң яхшы инженер, галимнәр дә авыл балаларыннан чыкты. Мин шуңа да балачакта малайларны эшләтеп, таләпчән булып үстерергә кирәк дим. Бөтен дөньяда шулай ул – Англиядә малайларны таяк белән кыйнап үстерәләр. Демократлар килеп, таякны тыйганнар иде – әлеге егетләр мәктәбендә тәртип бетте. Кабаттан таякны кайтардылар.

– Сезгә дә таяк эләктеме?

– Өйдә эләкмәде. Ә беренче сыйныфтан соң колхозда эшли башлагач тәтеде. Анда сиңа ике әйтеп тору юк, тибеп кенә очыралар иде. Берчак абыйга барып зарландым әле – таяк белән тунадылар, янәсе. Маңка малай, нәрсә сыртыңны куеп торасың, качып котыла алмагансың икән, миңа килеп зарланасы булма, диде абый. Мин андый тәрбиягә рәхмәтле генә. Чөнки без үскәндә гаделлек көчле иде. Һәр кешенең күңелендә тигезсезлек, гаделсезлек уелып кала бит ул. Безнең балачакта бөтенебез дә тигез идек – ярга ятып бер үк суны эчтек, бер телем ипине ашадык, бер үк таяк сыртка төште... Шуңа да ул минем күңелемә якты, җылы балачагым булып кереп калган.

Бер тапкыр шартламыйча, нинди химик?

– Югары уку йортындагы еллар нәрсәсе белән хәтергә теркәлгән?

– Мин мәктәптә укыганда ук чаңгы буенча район чемпионы идем. Институтта да чаңгы буенча уңышларым дәвам итте. Аннан тыш «Динамо» коллективында байдаркада йөздем. Икесеннән дә беренче разрядлы булдым. Иң якты истәлекләрнең берсе укытучым Алексей Иванович Разумов белән бәйле. Ул чакта институтта күп дигәндә 5 мең студент булгандыр. Разумов органик химия буенча лекцияләр укыды безгә – мин бүгенгәчә ул биргән «запас» белән йөрим. Атналар буе лабораториядән чыкмыйча эшләп ята идек. Химияне беләсең килсә – кулың белән тотып карарга, янып алырга, бер-ике тапкыр шартларга кирәк, һәр матдәнең исен-төсен аера башларга да лаборатория ярдәмгә килә. Хәзер әлеге уку йортында 40 мең тирәсе студент. Лабораториядә эшләү кимеде.

– Фән белән кызыксыну да бүген ташка үлчим. Бу очракта «еламаган балага имезлек бирмиләр» әйтеме урынлымы, Әхмәт Мазһарович, әллә ил сәясәте шуңа килеп төртеләме?

– Без укыган чорда доцент-профессорлар райком секретареннан югарырак хезмәт хакы ала иде. Алар шуңа да эшләренә башаяк чумган булган. Хәзер хезмәт хаклары... Минем хатын егерме елдан артык КХТИда доцент булып эшли – 12 мең тирәсе ала. Еламаган бала түгел бу очракта, елыйлар, сорыйлар, әмма ил сәясәтенә бүген фән кирәк түгел. Ә бит фән һәр нәрсәнең алдыннан атларга тиеш.

– Аның урынына бездә беренчелектә – спорт...

– Вакыт һәм акча беркемгә дә, беркайчан да җитми. Хәзер акча спортка күбрәк китә, Универсиада дип янабыз. Кирәк, спорт бик кирәк. Әмма аңа киткән акча күләме белән генә килешеп булмый. Спорттан бераз алып, фәнгә бирергә кирәк аны. Бу минем фикерем генә түгел, галимнәр фикере дә. Читтән сатып алынган спортчыларга акча түгелә бит – үзебезнекеләрне үстерсәк тә, дәшмәс идек әле. А.Тихонов, Г.Кадыйров, Г.Сәетхуҗин кебек спортчылар булса иде ул! Кара малайларны алып кайтабыз, ул бит спорт та түгел, бизнес. Шуңа да 60-70 нче еллар Россия тарихындагы иң рәхәт, иң матур чор булып хәтергә кереп калган. Космоска чыктык, икенче мәмләкәт булдык, бөтен олимпиадаларда беренчелектә булдык. Безнең өчен бер негр да, бер чит ил кешесе дә чыгыш ясамады.

Минем тамыр — монда

– 120дән артык патент, 40тан артык заводта сезнең технология буенча күкерттән чистарту җайланмалары... Бертуктаусыз эзләнү, бертуктаусыз иҗатмы бу, Әхмәт әфәнде?

– Углеводород чималы һәрвакыт үзгәреп тора. Кырык еллар элек чиста нефть тапсак, хәзер Татарстан нефте авырая. Составы гел үзгәреп торгач, фән һәрвакыт эзләнүдә. Биш елдан биш елга технология, аппаратураны үзгәртеп торырга кирәк. Производствоның ихтыяҗларын белеп торырга кирәк. Мин СССРның һәр нефть һәм газ заводын йөреп чыккан кеше. Ә хәзерге галимнәрнең бәласе – алар нинди юнәлештә эшләргә кирәген, заводның ни икәнен белми. Мин диплом алдыннан ярты ел заводта – Ангарскида эшләдем. Хәзер заводлар шәхси кулга күчте. Вузларның практика өчен акчалары юк. Бүген без галимнәрне такта янында әзерлибез. Приборны белә, химияне аңлый – әмма моны кайда, ничек кулланырга кирәк – анысыннан бихәбәр. Аннан, лаборатория белән завод арасында технология ясаучы институтлар бетерелде. Без әлеге нисбәттән академиядә шундый гамәли 25 институт булдырдык. Ә үземнең «иҗат», сез әйткән патентлар булдырган фәнни эзләнүләремнең иң кызыклы чоры 1994-96 елларга туры килә. Нефтьне күкерттән чистарту буенча технология Американың «Шеврон» фирмасына кирәк булды. Алар әлеге технологияне эзләп, төрле илләрдә булган, аннан безгә килеп төштеләр. Безнең технология аларны тулаем канәгатьләндерде. Шуннан соң Американың Хьюстон шәһәрендә ике зур җайланма – елына 4 млн тонна нефть эшкәртә торган ике завод төзелде. Без аларның зур проблемаларын чиштек. Хәзер елга 16 млн тонна нефть безнең катализатор белән эшкәртелә. 100 еллык тарихында Америка компаниясенең беренче тапкыр Россиядән технология сатып алуы булды бу. Без булдырдык!

– Моннан тыш Болгария, Иран, Фарсы култыгы, Германиядә Мазһаров исемле академикның эше кулланыла, аны танып беләләр. Хезмәтегезне туган җир бәяләдеме, Әхмәт абый, чит ил үзенең уңайлыклары белән кул изәмәдеме?

– «Шеврон»да эшли башлагач, алар миңа калырга тәкъдим иттеләр. Ләкин ничек чит илгә күченеп китим ди мин? Эше, тамырлары булган кеше китми ул. Әтием-әнием монда җирләнгән, институтым, миңа карап торган коллективым бар. Республика хезмәтемне күрде. Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә, Рөстәм Миңнеханов та фәннең кирәклеген бик яхшы аңлаучы, ярдәм итүче кешеләр. Әле миңа 70 еллык юбилеема гына иң зур орден – «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденын тапшырдылар. Әлеге орденның беренчесе Илһам Шакировка бирелгән булган икән. Татар халкы өчен иң күп эшләгән кеше ул! Әлеге рәткә мин дә бастым.

Без беркемнән ким түгел

– Гап-гади авыл малаеның шундый югарылыкларга ирешүенә нәрсә этәргеч булды дип саныйсыз, Әхмәт Мазһарович?

– Чеховның шундый сүзләре бар: «Я всю жизнь выдавливал из себя раба». Мин дә шулай эшләдем – коллыкны әллә кайчан куып чыгардым. Татар – гомер буе үзен мескен дип санап яшәүче милләт. Ә без беркемнән дә ким түгел. Мин моны бөтен дөньяны күреп кайткан, Сан-Францискодан Токиога кадәр профессор дип кабул ителгән кеше буларак әйтәм сезгә! Менә сез бала үстерүче яшьләр өчен дә киртлим, ким итеп үстермәгез балаларны. Татарлар ишектән керүгә, әнисе итәге артына поса, ә яһүд балалары ата-анасыннан алда түргә барып утыра. Сез дә шулай итеп үстерегез. Без бөтен өлкәдә беренчелеккә ирешә алырдай милләт – безнең Сәгъдиев, Сюняев, Нигъмәтуллин, Вәлиев кебек галимнәребез, армия генералы Гәрәев, сәнгать йолдызлары – Нуриев, Шаһиморатова, «Голос»та җиңгән ике кызыбыз бар. Без дөньякүләм беренче була алабыз.

– Моның өчен балачакта ук тәрбия нигезе булдыру зарурмы?

– Баланы эшчән һәм тәртипле итеп тәрбияләргә кирәк. Үз-үзен хөрмәт итәрлек булсын ул, мескенлек рухы кермәсен. Мине ул яктан Мөхәммәт абыем тәрбияләде – «син дөньядагы иң яхшы, иң беренче, иң булдыклы малай», ди иде ул. Аннан, ялкау булырга ярамый. Безгә беркем дә, бернәрсә дә китереп бирмәячәк.

Әти-әни янына кайтачакмын

– Әхмәт абый, әтиәниегез Сезнең уңышларны күрергә өлгердеме?

– Әтием мин V курста укыганда бакыйлыкка күчте. Әнием минем академик булганны күреп китте. Әмма мин алардан, туган авылым Саснадан ераклашканым юк. Сасна мәктәбе белән тыгыз элемтәдә – анда өч төрле стипендия оештырдым. Әтием, әнием янәшәсендә зиратта урын да алып куйдым, шунда кайтачакмын. Һәр кеше үз туган җиренә кайтырга тиеш. Авылыбызда әтием исемендәге мәчет бар – анда кереп намаз укыйбыз. Ул миңа көч бирә. Агач тамырлары белән көчле, диләрме? Кеше дә шулай ук – минем нигезем көчле, тамырым нык.

– Гаиләгез, кызларыгыз турында да ишетәсе килә?

– Хатыным Әлфия исемле, фән кешесе. Кызларым Сафия белән Наилә татар мәктәбен тәмамлады. Сафия Измирда һәм Америкада укыды, алты тел белә. Фарсы егетенә кияүгә чыгып, шалкан кебек ике малай үстерәләр. Кече кызым Наилә татарчаны миннән дә яхшы белә – Германиядә укыды, Лондонда эшли, шулай ук алты тел белә. Кызларыбызны бик яратып үстердек.

– Әхмәт Мазһарович, Татарстан Фәннәр академиясен җитәкләү, тормыш белән бер адымда атлау өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?

– Мин гомерем буе иртә сигездә – эштә. Үз эшемне белеп һәм яратып эшлим. Җитәкче булып, фәннең төрле өлкә кешеләре белән бер коллектив булып эшләү өчен, һәр тармакта гыйлемле булу зарур. Кем килә синең яныңа, син шул кеше телендә сөйләшә белергә тиеш. Икенчедән, кешелекле булу. Һәр кешегә кулыңнан килгәнчә булышырга тиешсең. Шунсыз син җитәкче түгел.

– Бәлки, минем сорау гаҗәпләнү тудырыр, әмма ут янып торган күзләрегезгә карап, Сезгә үз яшегезне биреп тә булмый. Тормышның ничек бар, шулай яратудан киләме бу?

– Кемнең кызык, үзе яраткан эше бар, аның күзе яна. Аның өчен академик булырга кирәкми – яхшы эретеп ябыштыручының, яхшы балта остасының күзе янып тора. Үз һөнәре, җирдә ныклап басып торырлык эше булсын кешенең. Гармония шуннан гына була ала. Коръәндә шундый сүзләр бар – иртәгә үләм кебек гыйбадәт кылырга, мәңге яшим диеп тырышып эшләргә кирәк.

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)тән: «Мөселман ялганлый аламы?» – дип сорагач, ул: «Юк», – дигән. Икенче бер хәдистә исә: «Килер заман, минем өммәтем бидгать гамәлләргә чумып бозылып бетәр, меңләп, аннан да күбрәк кеше тезелеп намаз укыр, әмма араларында бер генә мөселман да булмас», – диелә. Бу ике хәдисне нәрсә өчен язам, чөнки бу гамәлләр хәзер безнең арада киң таралган.

«Шуны да син белмәгәч, ник киләсең мәчеткә?»

БОРЧЫГАН МӘСЬӘЛӘ

Сөләйман ӘБЗӘЛИМОВ

Һәр мәчетнең үз туксаны туксан

Беренче очрак. Бер авыл мәчетенә өйлә намазын укырга бардым. Җыелган халык фарыз намазын бер рәткә тезелеп имамсыз-муллсасыз гына укыды. Намаздан соң болардан: «Ник мулласыз укыдыгыз, муллагыз кайда?» – дип сорагач, «Безнең имам 7сен үткәрергә китте һәм үзе булмаганда үзе урынына беркемне дә бастырырга кушмады», – дип җавап бирделәр. Ә имамсыз уку җәмәгать белән уку булмый ич инде.

Икенче очрак шулай ук бер авыл мәчетенең өйлә намазында күзәтелде. Бу мәчеттә, киресенчә, бөтен намазларны – фарызны да, сөннәтләрне дә муллага оеп укыдылар. Намаздан соң нигә шулай итүләрен сорадым. Болар миңа җәмәгать намазларын имамга оеп укырга дип язган китап күрсәтте. Дөрес язган, әмма сөннәт намазлары җәмәгать намазларына керми ич. Биредә мәчеттә укылган барча намазларны да җәмәгать намазлары дип уйлыйлар икән.

Өченче очрак. Тагын бер мәчеттә мондый хәл булды. Мәчетнең идәннәренә намазлыклар рәсеме төшерелгән палас җәелгән. Фарыз намазын укырга керешкән һәр бабай үзенең намазлыгы төшерелгән урынга баса. Әмма бабайлар арасында тагын бер кеше сыярлык ара кала. Мин болар арасына басарга теләгән идем, бастырмадылар, үз урынына басарга куштылар. Ә бит шәригать буенча кешеләр арасында бушлык калырга тиеш түгел, сафлар тыгыз булырга, җилкәгә җилкә тиеп торырга тиеш.

Дүртенче очрак. Бер мәчеттә уртага 1 метр киңлегендә кызыл палас җәеп куйганнар. Фарыз намазы вакытында бу паласка беркемне дә бастырмыйлар, ягъни кешеләр ике якка гына басалар да уртада буш урын кала. «Ни өчен шулай бүленеп басасыз?», – дип сорагач: «Имам теләсә кайчан кереп чыгып йөри алсын өчен», – дип җавап бирделәр. Ә бу гамәл шәригатьтә юк һәм рөхсәт ителми.

Бишенче очрак. Бер мәчеттә фарыз намазын укыгач, шәригать буенча икенче намазны укырга керешкәнче дип, икенче урынга күчеп баскан идем, ник басканыма үкендем. Бабайлар нәрсә генә әйтеп бетермәде. Алар каршында ваһһабчыга ук әйләндем.

Мин, имамнар һәм мөхтәсибләр бу язмамны укып, бәлки, җыелышлар ясап сөйләшер, хаталарны төзәтер дигән өмет белән, аңлатып язарга тырышам. Иншә Аллаһ, монда барысы да фәкать изге ният белән генә языла.

Мулла сүзе динне үтерә...

Бер мәчеткә яңа гына дингә басарга җыенган кеше килә. Бу кешене күргәч, мулла аңа иман яңартырга куша. Әмма, үзегез беләсез, яңа гына дингә басарга җыенган кеше каян белеп бетерсен ул догаларны. Мулла бу кешегә: «Иман да яңарта белмәгәч, нәрсә өчен мәчеткә килдең?» – дип әйтә. Шуннан бу кеше мәчеткә бүтән килми һәм намазга басмый. Менә шундыйлар аркасында безнең мәчетләребез буш. Бу факт.

Ә бер мәчеткә яшьләр күп йөри башлаган иде, чөнки укып кайткан яшь кешене имам иттереп куйдылар. Бераз вакыттан яшьләрнең күбесе намазларын бөтенләй ташлады. Моның сәбәбен соңрак төшендек. Бер җомга намазында яшь имам үз хөтбәсендә: «Әгәр берәү кеше үтереп йөрсә дә, зина кылып, аракы эчеп йөрсә дә, кыскасы, барча гөнаһларны эшләп, ширек кылып йөрсә дә, үз гомерендә бер генә мәртәбә (аңламыйча, юри генә һ.б.) Аллаһ бар дип әйтсә – шул җиткән, ул барыбер мөселман», – дип сөйләгән. Бу инде адәми шайтан, җәмәгать. Менә шундыйларның сүзләренә ышанып кешеләрнең күбесе намазга басмый, басканнары ташлый. Нәрсәгә вакытын әрәм итеп, намазлар укып йөрсен әле? Ул бит болай да мөселман!

Кайбер мәчетләрдә намаз вакытларын үзгәртеп уку гадәте киң таралган. Мәсәлән, иртәнге намазны 40 минутка вакытыннан алда укып куялар, ә өйлә намазын нәкъ зәввәл вакытында башлыйлар. Болар инде гөнаһтан да курыкмый, ширектән дә сакланмый. Вакыты кергәнче алдан укылган намазлар фарыз була алмый, нәфелдән генә санала һәм болай эшләү намазсыз калдыра. Сезгә, мәсәлән, иртәнге намазның фарызын укымаган гөнаһы язылып куела. Аллаһ сакласын!

Бүгенге бабайларның күбесе укымаган, дини гыйлемнәре юк. Игътибар итсәгез, алар хәтта бер доганы да дөрес укымыйлар. Хәреф хаталары гына түгел, кайбер сүзләрне дә төшереп калдыралар. Ә бу зур гөнаһ, аларның имам булып укытырга хаклары юк. Аларга оеп укысаң, намазлар кабул булмаска мөмкин. Шулай булгач, безгә нәрсә эшләргә соң? Надан залим муллаларга ияреп намазсыз калыргамы яки гыйлемле кешене имам итеп куяргамы? Бар андыйлар, барысы да бертөрле түгел. Сез нәрсә эшләр идегез? Ашыкмыйча гына, аек акыл белән уйлагыз әле. Ә бит шул надан залим муллаларны алыштырып булмый, алар үзләренә «көндәш» яшьләрне, «ваһһабчылар» дип яла ягып, төрмәләргә утырта. Бу факт! Әнә бер мәчеттә 3 ел эчендә генә дә укыган 5 имамны алыштырдылар. Сәбәбе – бабайларга ошамый, алар теләгәнчә укытмыйлар. Ә бит яшьләр барысы да Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча укытырга тырышты.

Бер район башлыгы: «Динне үзгәртмәгез, дөрес итеп тотыгыз, үзгәртергә юл куймагыз», – дип әйтә килә. Бу район башлыгына сорау бирер идем: кемнәр динне үзгәртә? Бабайлармы, әллә яшьләрме? Кемнең динне дөрес алып барганын, ә кемнең дөрес алып бармаганын каян беләсез? ОБСтан – «одна бабка сказала»данмы, әллә Коръәннәнме? Әлегә бабайлар динне үзгәртүчеләр булып чыга түгелме? Алар үзләре без Әбү Хәнифә мәзһәбендә дисәләр дә, башкача гамәл кылалар. Бер бабай: «Әбү Хәнифә китаплары дөрес язылмаган, алар диннән адаштырыр өчен язылган», – дип әйтте хәтта.

Бервакыт кыш көне иртәнге намазның фарызын укыгач, дисбе тартмыйча гына (өстәмә нәфел гамәл) эшкә ашыгып китә башладым. Өйлә намазларының сөннәтләрен мәчеттә укырга өлгерә алмый идем. Күп тә үтмәде, минем янга участковый килеп җитте. «Ник син намазларыңны бабайларча укымыйсың?» – дип сорый бу миннән. Тәмам аптырап калдым, нәрсә әйтергә белмим, нәрсә уйларга белмим. Һич көтмәгән идем бу хәлне. Ник алай әйтәсең, кем әйтте дигән соравыма, участковый: «Мәчеттәге бабайлар», – дип җавап кайтарды. Менә сиңа мә! Һич ышанасы килми, әмма каршыда участковый басып тора. Моңардан да каты явызлык, бозыклык бармы икән?! Рәнҗедем шунда шул бабайларга бинахак яла якканнары өчен. Хәзер шуларны күрмәс өчен мәчеткә дә сирәк бара башладым...

Көрәш ахырзамангача бара

Ислам диненә каршы аңың башланган көненнән бирле көрәш бара һәм ул ахырзаманга чаклы бетмәячәк. Ислам дине белән кәсеп итүчеләр күп, монафыйклар күп, тинтәкләр дә җитәрлек. Шуңа күрә бу язма күбесенә ошамаячак. Мин үскәндә, мәчетләр юк, бабайлар җомга намазын чиратлап өйләрдә укыйлар иде. Мин хәтерләгәнчә элгәреге бабайлар кебек укымыйлар хәзер намазларны. Бер авылда ике мәчет, икесендә ике төрле укыйлар. Имамнарның икесе дә үзләрен дөрескә саный, «Безнең бабайлар шулай укыйлар иде», – диләр. Әгәр дә элгәреге бабайлар да хәзерге бабайлар кебек төрле мәчеттә төрлечә намаз укыган булсалар, безнең бабайлар да динне бозган булып чыга түгелме? Минем тәкъдим шундый: Аллаһ Тәгалә каршында һәрбер кеше үзе өчен үзе җавап бирә. Безнең бурыч – дәлилләр китереп, дөреслекне кешеләргә җиткерү. Кабул итәрләрмеюкмы, аларның эше. Диндә көчләү юк. Беркемнең дә көчләргә хакы юк. Ә әлегә бездә киресе эшләнә, кешеләргә көчләп үзләренең бозык диннәрен тагарга тырышучылар үрчи. Аллаһ сакласын алардан. Иң беренче Коръәннең мәгънәсен аңлап укырга, өйрәнергә, фикерләргә кирәк. Аннары Пәйгамбәребезнең тормышын, шәригатьне өйрәнергә кирәк.

Алда язылганнарның сәбәбе – наданлык һәм тәкәбберлек. Башка диннәр дә башта дөрес булган, кешеләр аны үзгәртеп, бозып бетергән. Дини китапларын үзгәртеп язган. Фәкать Коръән китабын гына Аллаһы Тәгалә Үзе сакларга сүз биргән. Барча дөреслекне фәкать Коръәннән генә табып була. Аның да гарәпчәсен үзгәртә алмагач, татарчасын булса да үзгәртеп, үзләренә яраклаштырып язарга маташа адәми шайтаннар. Аллаһ сакласын алардан.

Аллаһ Тәгалә барчабызны да туры юлына бастырып дөрес гыйлемнәр бирсә иде, туры юлыннан адаштырмасын иде. Амин!

Гыйнварда намаз вакытлары

	Иртәнге намаз	Кояш чыга	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
25	07:19	08:49	13:02	15:12	17:02	18:32
26	07:17	08:47	13:02	15:14	17:04	18:34
27	07:16	08:46	13:02	15:16	17:06	18:36
28	07:14	08:44	13:02	15:18	17:09	18:39
29	07:12	08:42	13:02	15:20	17:11	18:41
30	07:11	08:41	13:02	15:22	17:13	18:43
31	07:09	08:39	13:02	15:23	17:15	18:45

Мәүлид ән-Нәби дөньявилаша

БӘЙРӘМНӘР

Мөселман календаре буенча һиҗринең өченче ае – Рабигуль-Әүвәлнең 12нче көне Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең туган көне – Мәүлид ән-Нәби бәйрәме дип исәпләнә.

Чынлыкта Пәйгамбәребезнең төгәл кайсы көнне туган булуы билгесез булганлыктан, Мәүлид аның бу дөньяны калдырган көненнән башлана. Күпчелек мөселман илләрендә бу бәйрәмне ай дәвамында зурлап уздыралар: шәһәрләргә Коръән аятьләре язылган плакатлар эленә, мәчетләрдә яки аш уздыру мәҗлесләренә җыелышып нәшидләр, мөнәҗәтләр көйләнә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)не мактап салаватлар әйтелә, вәгазьләр сөйләнә.

Пәйгамбәребез үзе исән вакытта беркайчан да туган көнен билгеләп узмаган. Шуңа күрә дә кайбер мөселманнар арасында бу бәйрәмне уздыру – дингә яңалык кертү, бидгать гамәл, дигән караш та яши. Әлеге бәйрәм тәүге тапкыр X-XI гасыр аралыгында Мисырда үткәрелә башлый.

Соңгы елларда бездә Мәүлид бәйрәмен үткәрү акрынлап сәхнәгә дә менә башлады. Быел исә 27 гыйнварда Россия мөфтиләр шурасы Мәскәүнең Крокус Сити Холл дип аталучы иң зур тамаша залларының берсендә танылган рус һәм чит ил җырчыларын җырлатып бәйрәм итәргә ниятли.

Мәүлид бәйрәменә багышланган төрле чаралар Казан мәчетләрендә дә үткәрелеп килә. Менә әле кичә генә шундый чараның берсе «Мәрҗани» мәчетендә узды. Ә 29 гыйнвар көнне шул ук «Мәрҗани» мәчетендә «Мөселман гореф-гадәтләрендә Мәүлид бәйрәме» дип исемләнгән түгәрәк өстәл узачак. Ә аңа кадәр бер көн алдан Камал театрында да бәйрәм концертының булуы көтелә. Былтыр концерт форматындагы шундый чара Тинчурин театрында узган иде. Бу бер яктан Мәүлид бәйрәме уңаеннан халкыбыз сәнгатен популярлаштыру булса, икенче яктан ничектер әлеге бәйрәмгә дөньявилык төсмере өсти кебек.

Сәхифәне **Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** әзерләде

Өйдә агач үстерәбез

Өй – хуҗабикәнең йөзе. Шуңа да һәркемнең аны матур, зәвыклы һәм үзенчәлекле итәсе килә. Ә аның өчен күпләр интерьерларына нинди дә булса үзгәреш кертергә тырыша. Кайвакыт гади генә бер картина, статуэтка яки чәчәк утыртылган ваза да йортны үзгәртеп куярга сәләтле бит. Шул исәптән топиарий да. Бу ни-нәрсә тагын дип уйга калдыгызмы? Топиарий ул – кулдан эшләнгән ясалма агач. Хәер, аның турында сезгә топиарийлар ясау остасы Мария ШӘРӘФИЕВА тәфсилләбрәк аңлатыр.

Дилбәр ГАРИФ

– **Мария, топиарий нәрсә ул?**

– Топиарий – интерьерны бизәү өчен төрле материаллардан ясала торган кечкенә генә агач. Күпләр аны якыннарына бүләк сыйфатында ала, кемдер үз фатирын бизәү өчен сатып ала. Чөнки ул йортка ямь кертү өчен үзенчәлекле аксессуар булып тора.

– **Топиарий ясау өчен син нәрсәләр кулланасың?**

– Аның өчен теләсә нинди материалны кулланырга була. Ясаучының фантазиясе генә булсын. Мине ул нәкъ менә шул ягы белән җәлеп итте дә инде. Кул астындагы бөтен әйберләр дә эшкә җигелә аны эшләгәндә. Ниндирәк композиция эшләргә була, нинди төсләр кулланырга, нинди материаллар сайларга, шуларны күз алдына китереп хыялга биреләсең. Мин үзем флористик органза, сүс, кипкән яки ясалма чәчәкләр, декоратив җиләк-җимеш, каһвә, төрле декор элементлары: атлас ленталар, күбәләкләр, муенсалар, пыяла мәрҗәннәр, шарлардан файдаланам. Санап та бетереп булмый, алар бик күптөрле.

– **Агачны утыртыр өчен нинди чүлмәк сайларга киңәш итәсең?**

– Ул топиарийның размерына һәм анда кулланыласы төсләргә ярашлы итеп сайлана. Нинди материалдан булуы мөһим түгел.

– **Агачның ябалдашы өчен шар нинди булырга тиеш?**

– Мин махсус пенопласт шар кулланам. Ә аңа беркетеләсе әйберләрне кайнар җилем ярдәмендә ябыштырам. Ул булмаса, шарны кул астындагы әйберләр белән ясарга мөмкин. Кәгазьләрдән йомарлам ясап, аны берничә тапкыр җеп белән уратып, күп итеп ПВА җилеме сылыйбыз. Монтаж күбеген дә файдаланырга була. Тик бу очракта шарны идеаль рәвештә тигез итеп эшләп булмый. Бер дә булмаганда, шулай итәргә кала. Тик мин шулай да махсус хэнд мейдны үз итүчеләр өчен эшли торган кибеткә барырга тәкъдим итәм. Кирәкле товарларны шуннан алырга була.

– **Агачның «кәүсәсе» дә бар бит әле...**

– Аның өчен теләсә нинди таяк бара. Таякны ябалдаш-шарга кайнар җилем белән беркетергә кирәк. Чүлмәккә исә гипс измәсе салып, шуңа таякны батырасың. Аннан инде үзең теләгәнчә бизисең.

– **Заказлар бирәләр диден. Сатып алырга теләүчеләр күпме соң?**

– Күп. Бигрәк тә берәр бәйрәм алдыннан сорыйлар. Кешенең якыннарын үзенчәлекле бүләк белән сөендерәсе килә бит, шуңа да миңа мөрәҗәгать итәләр.

– **Бәяләре ничегрәк?**

– 1300дән алып 1500гә кадәр. Бу инде эшнең катлаулылыгыннан һәм нинди материаллар куллануыннан тора.

Кулларыңнан куан

Безнең газета укучыларыбыз кул эшләренә бик оста. Аларның үз куллары белән тудырган могҗизаларын сезгә дә тәкъдим итәбез.

Кама Тамагы районы Олы Кариле авылының «Кыңгырау» балалар бакчасында да кул эшләренә зур урын бирелә. Бакча мөдире Галина Хикмәтуллина җитәкчелегендәге тәрбиячеләр коллективы балаларны кечкенәдән үк матурлыкны күрергә өйрәтә.

Аларның әйтүенчә, кул эше белән шөгыльләнү балаларда вак моториканы үстерергә, игътибарлылыкны арттырырга, фантазияне һәм зәвыкны баетырга, баланың иҗади сәләтен үстерергә ярдәм итә.

Тәрбиячеләре Гөлсем Димиева белән Альбина Әхмәтова ярдәмендә балалар курчакларга күлмәкләр тегеп-бәйләп кидерә. Көзге яфраклардан аппликацияләр, кәгазьдән, камырдан, балчыктан һәм ташландык материаллардан төрле нәрсәләр ясап карыйлар.

Тәрбияче апалары әлеге эшкә балаларның әти-әниләрен дә җәлеп итә.

Кулдан эшләнгән әйберләрдән алар ярминкә оештырып, аннан кергән акчага сабыйлар өчен яңа уенчыклар алалар.

Балтач районының Куныр авылында яшәүче Гүзәлия Васыйлова чәйдән яки печеньедан калган калай савытларга, искергән шкатулкаларга, көзгеләргә, фоторамкаларга, альбомнарга һәм башка шуның ише әйберләргә икенче гомер бирә.

Аларны калдык-постык тукымалардан ясалган төрле чәчәкләр беркетелгән тукыма белән тышлап куя. Әйтик, рәсемдәге шкатулканы печеньедан бушаган калай савыт дип кем генә әйтә алыр икән.

Гөл чүлмәген дә буядан калган савыт дип әйтмәссең. Фантазияң булганда һәм кулың ятып торганда, гади генә буяу савытына да җан өрергә мөмкин икән бит. Ә аңа Гүзәлия апа метрлап сатыла һәм ябыштырыла торган обойдан үзенчәлекле итеп бизәк кисеп алып ябыштырган.

ЙОЛДЫЗЛЫ АТНА

КУЧКАР (21.03-20.04)
Эш урыныңдагы мәхәббәт романыннан качарга тырышыгыз. Югыйсә ул карьерагызга аяк чалырга мөмкин. Тәмамлану алдында торган эшләр сезнең файдага уңышлы гына төгәлләнер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-20.05)
Аралашудан качарга кирәкми, теләсә нинди контакт та сезнең өчен кирәкле булырга мөмкин. Эштә сезнең кирәкмәгән буш эшләр белән шөгыльләнеп утыруыгыз хуҗагызга ошамас. Ә менә гаиләдә барысы да әйбәт булачак.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05-21.06)
Кемгә нәрсә сөйләвегез һәм аны ничек итеп җиткерүегезне контрольдә тотыгыз. Ни өчен дигәндә, нәтиҗәсе «Ватык телефон» уенын хәтерләтергә мөмкин. Ахырдан барысы да буталып, сез гаепле генә булып калырсыз.

КЫСЛА (22.06-21.07)
Атна очрашуларга һәм аралашуларга бай булыр. Элек хыялыгызга да китерә алмаган проектларга катнашу җае чыгар. Идеяләргә бай булуыгыз аркасында үзегезне лидер сыйфатында күрсәтә алырсыз.

АРЫСЛАН (22.07-23.08)
Яңа эшкә алына торсагыз да була. Моның өчен кемнеңдер яки нәрсәнеңдер этәргеч булуын көтеп утырырга кирәкмәс. Абруегыз белән аралашырга яратмаган кешене дә сөйләштерә алырсыз.

КЫЗ (24.08-22.09)
Язмыш сезнең ныклыкны тикшереп карар, һәм бөтен каршылыкны да җиңеп чыга алырсыз. Тик гайбәтләргә һәм имеш-мимешләргә колак салмагыз.

ҮЛЧӘҮ (23.09-23.10)
Юл куярга өйрәнегез. Ярдәм тәкъдим итсәләр, каршы килмәгез. Һәр көнегезне алдан ук планлаштырсагыз, куйган максатыгызга тизрәк һәм җиңелрәк ирешерсез.

ЧАЯН (24.10-22.11)
Карарлар кабул иткәндә сездән активлык һәм җаваплылык хисе сорала. Иҗадилык һәм яңа идеяләр эшчәнлегегезне киңәйтер. Эшегезнең нәтиҗәләрен көткәннән соңрак татырга туры килер.

УКЧЫ (23.11-21.12)
Тәвәккәллек һәм алдан күрүчәнлегегез аркасында гаиләдәге проблемаларны уңай хәл итәрсез. Эшлекле кешеләргә, кайсы партнеры белән генә аралашса да, уңыш елмаер.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01)
Хуҗагыз белән сөйләшүдән соң киң мөмкинлекләр ачылыр. Ял көннәрендә дусларыгыз белән бәйрәм оештыру күңелсез уйлардан арынырга ярдәм итәр, кәефегезне күтәрер.

СУКОЯР (21.01-19.02)
Керемнәр турында уйлап, атнагыз сизелми дә үтәр. Ә сез әле һаман бер карарга да килә алмыйсыз. Атна ахырында балаларыгызга карата игътибарны арттырыгыз.

БАЛЫК (20.02-20.03)
Атна башында үз тәҗрибәгез белән уртаклашу мөмкинлеге туар. Бер эшне тәмамламыйча икенчесенә күчү гадәтен ташлагыз. Ял көннәрендәге очраклы танышу көчле мәхәббәт романына китерер.

Сәхифәне Дилбәр ГАРИФ әзерләде

АРЫШ БАСУЫ, МЕРСЕДЕС, ӘТКӘЙ БЕЛӘН ӘНКӘЙ...

Татарстанда клиплар 10 мен сумнан 1 млн сумга кадәр

Хәзер эшләп килүче татар телле музыкаль каналларны карагач, кызык бер күренешкә тап буласың. Менә дә шәп ул бездәге клиплар! Андагы тематика, андагы фикер киңлеге, андагы фантазия...

БЕЗДӘ ШУЛАЙ

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Бер сүз белән – юк. Иң беренче клип булса, без җырчының бөтен нәселыруы белән танышып чыгабыз. Ул авылга кемнеңдер машинасын алып торып кайта, аны каршы алалар, табын тирәли җыйнаулашып утырып чәй эчәләр. Икенчесе булса, ул, һичшиксез, ялга барачак. Һәм ул һичшиксез Төркия булачак. Диңгез буенда ул кабат берәр элиталы-валюталы машинада җилдерәчәк, диңгездә су чәчрәтәчәк, ялан тәпиләп ярдан йөгерсә дә, гаҗәп түгел. Өченчегә үк барып җитүче җырчылар бармак белән санарлык – бердән, аның кадәр ул гомер җырлаучылар сирәк, икенчедән, чын җырчыларыбыз интегеп клип төшереп тормый. Аларга инде капка төбендәге баганага сөяләп җырласалар да ярый – барыбер яратып тыңлаячакбыз. Ул яктан арыш басуларында, агач төпләрендә утырып-басып җырлаучы асыл җырчы егетебез **Филүс Каһиров** үзе бер хәзинә. Филүс башкарган мәгънәле, сәнгати җырларга Мерседес ише «оправалар» ни хаҗәтемә кирәк ди? Нәкъ менә классикларыбыз стиле, **Бигичев, Шакиров, Ваһапов**лар дәвамы.

Алтынга манчылып алырга тырышучылар исемлегенең очы-кырыена чыгышлы түгел. Кемдер кыйммәтле кунакханәдә җаваплы-җавапсыз-хыянәтле мәхәббәт тарихын барлый, кемдер кара күзлек киеп, кабриолетларда җилдерә, кемдер туган ягына кайтып, «кеше булуын» күрсәтә. Кайчагында, нүҗәли шуннан кала фантазия эшләми дә, шуннан ары үсеп булмый дип гаҗизләнәсең. Дөрес итеп мылтык та тота белмәүчеләр белән сугыш күренеше күрсәтергә маташучылар да үзе бер кәмит. Аңа бит инде сабын куыгы яратучы хатын-кыз гына түгел, ир-атлар да күз сала.

Кыйбат инде, кыйбат хәзер бөтен нәрсә. Җыр яздыру да (аның текст хакы бер мең сумнан өч меңгә кадәр, көй яздыру өч меңнән унбиш меңгә кадәр диләр), клип дигәннәре дә. Клип төшерү бездә уртача утыз мең тирәсе инде ул. Ул утыз меңгә әллә ни аткарып булмый, әлбәттә. Төянеп авылга кайтып китү аңлашыла да. Әмма юктан да кәнфит ясаучылары юк түгел. Гадилек, юмор салынган клиплар үзләре бер матурлык бит. Әнә, **Рөстәм Закиров**ның «Тәгәрәткән бәрәңге»се кемгә ошамый калган ди? Иске кием-салымы белән бакчада бәрәңге утыртып, алып ятканны кайсы авылдан чыккан кеше карамый калсын. Рөстәмнең бөтен туган-тумачасын күрергә дә каршы түгел бу очракта.

Иркәнең «Карлыгачта хәбәрем юк» клибы ярата алды. Позитив һәм бетте-китте. Дүрт бала, пәп кенә итеп торучы ирең, зур өең, машинаң – монда Стас Михайлов публикасына керүче бөтен хатын-кыз экранга берегә дә куя. Бу бит хатын-кыз бәхете формуласы! **Хәния Фәрхи**нең бу нисбәттән гел сюрпризлар белән шаккатырып торучы ирен клипка кертүе урынлы. Ир ир инде ул – әйбәт булгач, аны да карыйбыз.

Иҗатын яратсам да, **Айдар Галимов** клипларын ошатам, дип әйтә алмыйм. Башта компьютер графикасы белән мавыгып алды Айдар, әле ярый бу «Бер мизгел» җырына төшерелгәне үзенең иҗат юлын үз эченә алган да, күңелгә ятты. Алайса гафу итәсе юк иде Айдарны...

Салават артык клиплар белән мавыкмый – соңгыларының берсе – «Юк, юк» җырына төшерелгәне Камал театры артистлары уйнавы, мәгънәлелеге белән үзенә тартты. Нәфисә белән Радик елаттыра белә анысы...

Яшьләрдән **Салават Миңнеханов**ны телгә алып китсәң ярыйдыр. Клиплары үзенчәлекле булды аның. Әмма соңгы арада әллә артык чәчелде Салават, аннан яңалык та, җыр да, клип та түп-түп. Клиплар мәсьәләсендә **Раяз Фасыйхов**ка да эшләү җитенкерәми. «Корстон»да бер клип төшерде дә, вәссәлам. Ә юкса күпме матур, мәгънәле җырлары бар Раязның! **Азат Фазлыев**ның «Картлар йорты» үзенә тартты, бәгырьгә чиртте. **Илназ Баһ** та быел шуңа охшаш бер клип төшерткән икән. Әмма бер ботканы ике кат ашыйсы килми инде. **Алия Исрафилова**ның фантазиясен эшкә җигүе сизелә, романтикасы бик нечкә эргәдә. «Әтиле, әниле ятимнәр» клибы гына да – бу заман көзгесе.

> ***Бәлки, студиядә җырлаганда мин бер даһидыр, әмма мин сәхнәдә җырлаганда, даһи ул — тамашачы.***
>
> ***Алла Пугачева***

Сикергәләп, биеп, чабып төшкән клипларга да ис китми. Ул һаман шул бер нәрсә белән икенче җитешсезлекне капларга маташу кебек килеп чыга. Тавыш шунда уртача инде, ну мин бит әле бии дә беләм, янәсе. Салават әйтмешли, киенеп бетмәгәнме, чишенеп бетмәгәнме килеш төшүчеләрне дә кабул итеп бетермибез. Юха елан кебек караватка ятып җырлыймы ул, кемгә дә булса елышамы. Матур түгел. Билдән югары шәрә килеш сырпаланышып утырган **Рәфинә Ганиуллина белән Габделфәт** клибына да шуңа тәнкыйть күп булды. Бәлки, шоу-бизнеска андый иркенлек тә кирәктер, әмма татарның үз кысалары бар инде, ни хәл итәсең.

Кайчак кирәкме соң ул клип дигәннәре дип тә уйлап куясың. Кайбер җырчыларның аны бөтенләй санламауларын да беләм мин. Яңалыгы машина, коттедж, туган-тумача, туй видеосына кайтып калса, режиссер кулы уйнаган, талантлы кеше уйлап тапкан инсценировкасы булмаса, әлбәттә, кирәге ташка үлчим ул клипның. Камиллеккә омтылыш булсын иде бит, ә? Шәп, җитми калды, дигән тансыклау да кирәк тамашачыга...

Алмаз НУРГАЛИЕВ, клипмейкер:

– *Татарстан өчен клиплар төшерү әлегә кыйммәт булып санала. Ә болай бездә клип төшерү хакы 10 мең сумнан 1 млн сумга кадәр. 500-600 мең бюджетлык клиплар да шактый. Соңгы ике елда төшерелгән клипларның 60-70 процентын минеке дип әйтә алам. Клип төшерү буенча күбрәк яшьләр йөри. Алар әлегә үз урынын тапмаган, әмма актив рекламага мохтаҗ категория. Клип бит ул икенче төрле реклама дигән сүз. Ә һәркөн телевизор экранында балкыган, аншлаг белән концертлар куйган атаклы җырчыларыбызга клип ул үз дәрәҗәсен ассызыклау өчен генә кирәк. Мисалга, Салават, Хәния, Айдарлар клипсыз да халык күңелендә яши. Шуңа да клипмейкерлар яшь-җилкенчәк, әле сәхнәгә күтәрелеп кенә килүче җырчылар өчен күбрәк кирәк.*

Илдар КЫЯМОВ, «Яңа Гасыр» телевидениесенең «Хәерле иртә!» тапшыруы алып баручысы:

– *Безнең һөнәр шундый инде – тапшыруда халыкка җырчыларның яңа клипларын тәкъдим итәбез. Ә клипларның эчтәлеге, мәгънәсе ягыннан аксаганнары шактый. Үзе сүзен, үзе көен язганнар заманында яшибез, үзләре үк ялт кына клип сценариен да әтмәлләп ата андыйлар. Була икенче төрлесе – биюе дә, сценарие дә, җыр тексты да бер-берсенә үрелеп баручы эксклюзив җыр клиплары. Алары гадәттә имиджмейкер белән эшләүче яшь җырчыларныкы була. Һәм алар гадәттә Казанда төшерелми. Ә бездәге җырчыларның бер-берләрен кабатлаулары, тема берлеге күзгә чалына. Мин Резидә Шәрәфиеваның «Йөрәктә йөрткән сүзләр күп» клибын яратып карыйм. Күңел тула аны караганда. Әлеге җыр Уфада төшерелгән. Бездә бит клип төшерә белмиләр, дип сүгеп тә булмый. Җырчылар һәрвакыт эзләнүдә. Аның өчен өйрәнү мәктәбе юк. Әлеге мәктәпне булдырырга кирәк. Аннан инде гел яхшы клиплар белән генә мактанып утырып булачак.*

Рамил ТӨХВӘТУЛЛИН, Татарстанның халык артисты, режиссер:

– *Ошамаганнары бар, кызыклы төшерелгән клиплар да очрый. Аны бит яхшыяманга да аерып булмый. Җырчы, аның җыры нинди клибы да шундый дигән сүз. Һәр кешенең күзаллавыннан тора. Мәсәлән, Раяз кебек профессионал, шәп җырлаучының клибы ничек начар була алсын ди? Җырчы примитив икән, клибыннан да әллә нәрсә көтеп булмый. Клип бит инде ул драматургия салынган видео дигән сүз. Мәгънәле җыр, талантлы җырчы икән, ул инде аның сценариена да зур әһәмият бирәчәк. Әмма мин кемнәрнедер аралап, тикшереп утырасым килми, мин аларның бөтенесе белән таныш та түгел. Үземнең исә режиссура нисбәтеннән берничә клибым бар. «Юлчы»да драматургия бар дип беләм...*

МӘСКӘҮЛӘРДӘН СӘЛАМ

Басков һәм Волочкова уены

«Секс – матурлык өчен иң беренче кирәкле фактор», – дип уңга-сулга үзенең интим тормышын сөйләргә тайчынмаган балерина **Анастасия Волочкова** турында күптән берни дә ишетелми дип хафаланасызмы? Менә яңа гына табадан төшкән «каймак» – гыйнвар башында гына гламур йолдыз Мальдив утрауларында җырчы, Россиянең төп блондины – **Николай Басков** белән мәхәббәт уены куертып кайтты. Интернет челтәргә эленгән фотоларга карау белән ирен читенә елмаю куна – булса да була икән шуның кадәр назлыбикә! Үбешеп-сырпаланып төшкәнме ул, караватта Коляның аякларына «уралганмы», суда кети-мети уйнашамы... Булдырасың, Настя, сиңа килешә! Коляны гына тулаем бозып ташлама, яме...

Ельцинның чираттагы «йөрәк чире»

Кече **Борис Ельцин** – илнең иң күз атып торган буйдагы тагын бер мәхәббәт кармагына капкан әле, җәмәгать. Сен-Барт – миллионерлар утравында аны 23 яшьлек модель Олеся Сенченко белән күргәннәр. 29 яшьлек Боря өчен бу мәхәббәт романнарының сан буенча ничәнчеседер, әмма Олесяны ул Роман Обрамович уздырган яңа ел кичәсенә дә ияртеп килгән. Шушы ук кичәдә Борисның якыннары – әнисе Татьяна Дьяченко белән аның ире Валентин Юмашев та катнашкан. Әллә бар да туй тарафларына барадыр әле, кем белә.

Сергей Филин дога өмет итә

Зур театрның балет буенча сәнгать җитәкчесе – **Сергей Филин**нең йөзенә кислота сибү темасы соңгы араларда иң шау-шу тудырган вакыйгаларның берсе булгандыр. Әлегәчә бу коточкыч хәлне оештырган кешенең кем икәне билгесез булып кала бирә. Сәбәпләрне төрлечә юрыйлар – кемдер яңа ел премияләренең дөрес бүленмәве, кемдер интернет челтәрдә Филинның ярдәмчесе Руслан Пронин турында бик үк җылы булмаган сүзләр әйтүе, кемдер исә власть өчен көрәш нисбәтендә Цискаридзе исемен дә телгә ала... Әлегә хастаханәдә ятучы Сергей үзе: «Минем өчен дога укыгыз. Дөньяда могҗизалар да була...» – дигән.

Сәхифәне Гөлнара ҖӘЛИЛОВА әзерләде

Мәдәни ГАВАМ

Соңгы вакытларда юмор остасы Илсур МОРТАЗИН тамашачыны юксындыра башлады. Ни дисәң дә, җор телле, теләсә кемне елмайта ала торган сәхнә кешесен халык ярата шул. Аның кайларда йөрүе, ниләр белән шөгыльләнүе хакында И. Мортазинның үзе белән сөйләштек.

«Җитешсезлекләрне сәхнәдә сөйлисе килми»

ИҖАТ ЮЛЫ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Илсур, Казан сәхнәләрендә озаграк күренми тордың шикелле. Аның сәбәпләре бармы? Бөтенләй сәхнәдән китмәгәнсеңдер бит.

– Соңгы елларда без хатыным Мәүлидә белән Зөлфия һәм Мөхтәр Минһаҗевлар төркемендә эшлибез. Күбрәк авылларда йөрергә туры килә. Мәскәүгә һәм Нижгар якларына туйларга еш чакыралар. Февральдә Казанда чыгыш ясарга әзерләнәбез.

– Бүген халыкны билет сатып кына концертларга тартып буламы соң?

– Авыл җирләрендә кеше хәзер начар яшәми, әмма барыбер мескенләнергә ярата. Бер-берсе белән аралашмыйлар. Халыкта сәнгать чаткысы сүнде. Байлары, үзләрен күрсәтү өчен, концертны Казанга килеп карый. Әле дә ярый шул өлкәннәребез бар. Сирәк кенә булса да, яшьләр кызыксына. Безгә генә түгел, популяр артистларның концертына да шулай аз йөриләр. Шуңа күрә җир җимертеп эшләргә күңел бармый. Мин болай да төшенкелеккә бирелә торган кеше.

– Ә читтә ничек кабул итәләр?

– Мәсәлән, Пензадагы авылларда хәзерге татар җырчыларын бөтенләй белмәүләре безне гаҗәпләндерде. Алар бары тик өлкән җырчыларны гына таный. Әллә башкалары белән халык үзе кызыксынмый, әллә җырчыларыбыз анда барып җитмәгән.

– Илсур, син сәхнәдә күбрәк юмор сөйлисең. Аларны үзең дә язасың. Бу язучы булмаганнанмы, әллә күңелгә ятышлысы табылмагангамы?

– Шаян хикәяләр бар бездә. Әмма аларны сәхнәгә яраклаштырып язучы сирәк. Бездә бит рус эстрадасындагы кебек түгел. Чәйнәп каптырмасаң, йота белмиләр. Тормыштагы җитешсезлекләрне күп күрсәк тә, аларның бөтенесен дә сәхнәдән сөйләп булмый, чөнки халык ул проблемалардан болай да туйган. Тамашачы концертка күңел ачарга килә.

– Сәхнәдә беренчеләрдән булып рус җырларына охшатып язылган көйләрне дә син күрсәтеп бирдең. Үзешчән композиторлар колак салдымы ул тәнкыйтькә?

– Юк, бүген ул көйләрне аерып ала торган түгел. Татар көе бик аз хәзер. Безнең тәнкыйтькә игътибар да итми, ишетми дә ул көй язучылар.

– Синең хатының Мәүлидә дә көйләр яза. Аларны кемнәр башкара?

– Безнең уртак иҗат җимешләре дә бар. Концертларда аларны бергәләп башкарабыз. Тиздән җыр дискыбыз дөнья күрергә тиеш. Әгәр җырларын башка җырчылар ошата икән, Мәүлидә аларны бүләк итеп бирә. Башкалар җырласа, безнең өчен сөенеч кенә. Шушы арада Бәширә Насыйрова берничә җырын сорап алды. Әле күптән түгел Нижгар өлкәсендәге бер авылга багышлап җыр яздырганнар иде. Бик матур килеп чыккан, диделәр. Без мишәр булсак та, үткенлек тә, әрсезлек тә юк. Сәхнә кешесе өчен алар бик кирәк сыйфатлар югыйсә.

– Илсур, әгәр абыең Фирзәр үзеңне сәхнәгә тартмаган булса, бүген үзең нәрсә белән шөгыльләнер идең?

– Мин бит, Лениногорск сәнгать училищесын тәмамлап, рәссам булырга хыялланып йөргән кеше.

– Бүген ул һөнәреңнән файдаланырга туры киләме?

– Әле күптән түгел аш бүлмәсенә ремонт ясыйсы иттек. Шуңа күпме акча китәсен белү өчен Мәүлидә осталар чакыртып китергән дә, тегеләр утыз мең сумга төшәчәген әйткәннәр. Шуны ишеткәч, үзем дә өнсез калдым. Шуннан соң, тукта әле, алар кебек мин дә булдыра алам бит, дип эшкә тотындым. Дизайнын да үзем ясадым. Әйбәт кенә килеп чыкты үзе. Килгән кеше бик ошатып китә.

– Үзеңә заказ бирүчеләр юкмы соң әле?

– Бирсәләр дә, куркып тормыйм инде хәзер. Баштагысы уңышлы килеп чыкса, эшлисе генә килә бит ул.

– Сезнең улыгыз Робертның да талант иясе икәнен беләбез. Бүген ул ниләр белән шөгыльләнә?

– Без Робертка, сәнгатьтән туеп читләшмәсме дип, уналты яшендә үк музыка җиһазлары алып биргән идек, ә ул, киресенчә, тартыла башлады. Үзе көйләр яза, татар, рус, инглиз телләрендә җырлый, аранжировка да ясый. Раяз Фасыйхов белән аралашып киткәннән соң татар җырларына мәхәббәте уянды аның. Музыка мәктәбендә укыган җиреннән, миңа анда кирәк нәрсә юк, дип ташлаган иде югыйсә. Роберт үзебез белән гастрольләргә йөри. Аның тавышы үзенчәлекле. Тамашачы килеп: «Улыгыз үзегездән уздыра», – дисә, сөенәбез генә. Ул ди-джей булып та эшли. Бүгенге көндә технология университетында укый. Факультетның мәдәни чараларын оештыручы. Университетта уен кораллары ансамбле оештырды. Үзе гитарада уйный. Аларны Универсиадада чыгыш ясау өчен сайлап алганнар. Роберт студентлар арасында узган конкурста узган ел беренче урынны яулады. Апрель аенда ул Сочига волонтер булып барачак. Әнә шулай улыбызның уңышларына сөенеп яшибез.

НИ ХӘЛЕГЕЗ БАР?

Айдар ХАФИЗОВ, Татарстанның халык артисты:

– Мәскәүне шаккатырып кайттык әле. Спектакльләребезгә керә алмыйча кайтып китүчеләр дә булды. Кызыбыз Айсылу Мәскәүдәге телевидениедә «Мөселманнар» тапшыруын алып бара, «Татар иле» газетасы белән хезмәттәшлек итә. Үзем, репетицияләр булмаганда, балыкка йөрим. Буалылар, якташлык җәмгыяте кичәсен үткәргәндә, режиссер булырга тәкъдим ясадылар.

Миңгол ГАЛИЕВ, Татарстанның халык артисты:

– Шушы арада гына Мамадышта Шәйхи Маннурны искә алу кичәсенә кайтып килдем. Язучылар һәм башка кунаклар районндагы 3 нче гимназиядә балалар белән очрашты. Үзем берничә көннән соң анда музыка сәнгате буенча да чыгыш ясадым. Яшь тамашачы театры режиссеры Ринат Әюпов артистларга музыка дәресләре бирергә чакырды. Берничә көн элек «Казан сандугачы» конкурсында жюри әгъзасы буларак катнаштым.

Резеда ВӘЛИЕВА, шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе:

– Әлегә беркөе яшәп ятам. Авырып та алам. Шигырьләр, җырлар язам. Әтнә мәктәбенә очрашуга барып кайттым әле. Балалар бакчаларына, мәктәпләргә очрашуларга чакырып торалар, Аллага шөкер.

МӘДӘНИЯТ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Шаляпинның 140 еллыгына багышлана

Быел Ф. Шаляпин исемендәге XXXI Халыкара фестиваль Дж. Вердиның «Аида» операсы премьерасы белән ачыла. 1-16 февральдә узачак әлеге фестиваль бөек җырчының 140 еллыгына багышлана. Анда Румыния, Америка, Италия, Франция кебек илләрдән биш йөзләп кеше катнаша. Шуларның 35е җырчылар. «Риголетто» һәм «Турандот» операларында дирижерлык итү өчен якташыбыз Айрат Ишмуратов та кайтачак. 13 февральдә – Ф. Шаляпинның туган көнендә «Борис Годунов» операсы яңгыраячак. Заманында бөек җырчы үзе дә анда төп партияне башкарган. 14-15 февральдә җырчылар катнашында Гала-концерт узачак.

Безнекеләрне яратып калдылар

Казанда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Светлана Ишкузина җитәкләгән «Счастливое детство» бию коллективы Һиндстанда булып кайтты. Алар анда Һиндстан хөкүмәте ярдәме белән оештырылган фестивальдә катнашты. Әлеге чарада чыгыш ясау өчен унсигез илдән дүрт йөз бала килгән иде. Россиядән ун ансамбль чакырылган. «Счастливое детство» үз репертуарындагы «Татар гармуны», «Казан егетләре», «Казачок» һ.б. биюләр күрсәтте. Катнашучыларның һәркайсы үз әләмнәре белән һәм милли киемнәрдән чыгыш ясады. Безнең биючеләрне тамашачы аеруча яратып калды.

Режиссер Әлмәтне үз итте

Әлмәт Татар дәүләт драма театрында Б. Брехтның «Туй» әсәрен сәхнәләштерделәр. Аны театр директоры Фәридә Исмәгыйлева тәрҗемә иткән. Коллектив күптән түгел Театр әһелләре берлеге грантына ия булган иде. «Туй»ны Санкт-Петербургтан килгән режиссер Искәндәр Сакаев сәхнәгә куйды. Әлеге режиссер моңа хәтле дә бу театрда «Гашыйк Кәриб» әсәрен сәхнәләштергән иде. Ул спектакль тәнкыйтьчеләр тарафыннан да югары бәя алды.

Әкияткә кунакка

«Әкият» Татар дәүләт курчак театрында бүген күренекле язучы Равил Бохараевны искә алалар. Шул уңайдан ул язган «Апушның тылсымлы төшләре» әсәре буенча куелган спектакль дә тәкъдим ителә. Анда баш рольне Татарстанның атказанган артисты Данил Үтәшев уйный. Әлеге актер 30 гыйнварда үзенең 60 яшьлек юбилеен каршылый. Заманында Җаектан килеп, 35 ел гомерен курчак театрына багышлаган артистны сәхнәдәшләре, театр әһелләре тәбрикләргә җыена.

ШӘХЕСЛӘР ТОРМЫШЫННАН

Т-Т-Т

Берничә яшь язучы белән сөйләшеп утырганда, Илдар Юзи табышмак әйтә:

– Татар өчен зур хәрефләр белән язылa торган өч «Т» нәрсә ул?

Кемдер:

– Трамвай-Троллейбус-Техникум! – ди.

– Юк! – ди Илдар.

Бик озак эзләсәләр дә, яшьләр табышмакның җавабын таба алмыйлар.

– И наданнар-уңмаганнар! – ди Илдар. – Татарча өч бөек «Т» бар: Тукай, Такташ, Туфан!

Сәхифәне Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде

Кеше көлдерәм дип, бөтенләй үк шәрә калырга димәгән.

Бибәл Норел

ХИКМӘТЛЕ КОТЛАУЛАР

ТМИН (Туфан МИҢНУЛЛИН)

Бурсык авылында яшәүче алдынгы карашлы, берничә буын яшь буынны тәрбияләгән укытучы, яраткан бабаебыз Колсәетов Гыйбадулла Коләхмәт улына 80 яшь тула. Кадерле бабаебыз, Сине олы юбилееең белән котлыйбыз. Киләчәктә дә үрнәк татар гаиләсенең куанычы булып яшә!

Улың Фердинант, киленең Гертруда, оныкларың Эрик, Варвара, Лимузин.

* * *

Дустыбыз Гөрлия! Кияүгә чыгып, башлы-күзле булуың белән котлыйбыз, Бәхет телибез. Исән-сау гына әйләнеп кайтырга язсын. Привет Вадиму.

Дусларың.

* * *

Любимуй внучик Рубчик! Жилаем тибя агромного ысчастия. Мы надиемся, что ты будиш дастуйным прадалжателем нашиго замичатилново рода.

Твоя любимая дедушка Солимгарей и бабушка Хуббуниса.

Башыма тай типмәгән

Әчтах СӨРГӘЛИ

Җитте – бүтән эчмим. Җырчылары да: «И Мөслим! Бүтән эчмим!» – дигән шикелле җырлый бит әнә... Минем аркада хатын җәфалана. Үземне әйткән дә юк. Югыйсә, ничә мәртәбә сүз бирдем бит: «Эчмим, авызга якын да китермим!» – дидем. Хатынга гына күпме тукыдым. Юк, ышанмады хатын. «Синең кайчан сүзеңдә торганың бар соң, җанкисәккәем?» – генә диде. Сүздә торган чакларым булгалады инде анысы. Әле былтырларны гына: «Синең миңа сыңар яулык та алып кайтып биргәнең юк бит», – дип зарланыпмы зарланган иде. Мин исә – сүземдә тордым. Беркөнне базардан сатып алып кайттым яулык. Бәһасе кесәгә сукты сугуын... «Рәхәтен күр, үз башыңда тузарга язсын!» – дидем хатынга. Аның гына исе китмәде: «Ярар, минем әнигә нәкъ менә шундый әбиләр яулыгы кирәк иде», – диде дә яулыкны битараф кына алып куйды. Ир кадерен белмәгән ул хатын-кыз! Аларга шул зарланырга гына булсын... Минем: «Эчмим», – дигән сүземә дә ышанмый тора бит әле менә. Саңгырау ана эт тә аңлардык итеп әйттем, югыйсә...

Тамак төбе кымырҗып авырта. Юк, моннан соң эчмим. Суыткычтагы шешәнең гурласыннан (мишәр әйтмешли!) гелән-гелән салкын сөт эчәргә башыма тай типмәгән лә минем! Юк, бүтән эчмим ул боздай салкын сөтне!

Гурлама салкын тидерә-тидерә туйдым инде. Аракыга күчмичә булмас. Ичмасам, хатыннан авыр сүз ишетмәм...



Җырчы шагыйрь

ӘПКӘЛИ (Фаил ШӘФИГУЛЛИН)

Суыткыч эчендәге бушлык шагыйрьнең профессиональ йокыдан шешенгән күзләрен өтеп алды.

– Тәк, – дип, бәрәңге борынын пыршылдатып куйды ул, – суыткыч бушаган, берәр хәллерәк колхозга җыр язар вакыт җитте.

Шагыйрь колак мендәре хәтле генә корсагын сыпырып, стенага келәм урынынаябыштырылган Татарстан картасы янына килде. Инде кайсы район белән килешеп карарга? Арчаның җыры искермәгән. Актанышның исеме җырдан төшми... Алпар, һәй, Әлки яклары Нәби Дәүли безгә бирәме соң! Алпарныкылар төсле җиде сарык суеп бер ай буе сыйласалар, Әлкинең бөтен авылын җырга күмәм, дип әйтә ди. Кара әле, ул Нәби Дәүлинең акчасы күптер, ә? Әле өч капкалы авылга җыр язып та кулына өч йөз тәңкә акча тоттыралар. Ә Нәби Дәүли Өфе тикле калага җыр язган кеше...

Борындыкка... юк, өч җыр житәр аларга, барыбер җыр кадерен белмиләр, берсен дә җырламыйлар... Тәк, Буа... Буам!.. Буама!... Тукта, Барлас Камалов язды бугай инде моны... Шушы чаклы зур республикада, әйтергә кирәк, өч орденлы Татарстанда җыр язардай авыл калмаган диген, ә?! Болайга китсә, шагыйрь халкы ничек көн күрер икән? Композиторыма шылтыратып карыйм әле, берәр заявкасы юкмы...

– Алло?
– Нәрсә дисең?
– Бармы
– Күпме кирәк?
– Шәбрәген инде.
– Бер авыл 300 сум һәм сарык ... тәкъдим итә.
– Тагын, – диде Шагыйрь, нәүмизләнеп. – Әзрәк икән шул. Борындыклар, әнә, шуның белән берлектә, почет грамотасы да биргәннәрие.
– Ихтыярың. Алайса Нәби Дәүлигә шылтыратам.
– Кара инде, бер дә юморны кабул итмисең хәзер. Үзем язам. Авылларының исемен әйт тә...
– Базарлы Матак. Әлкинең башкаласы.
– Чынлап мәллә?
–Теләсәң, Котлы Бөкәш бар – Балык Бистәсеннән, Югары Осланнан – Мәкәево... Шундыйлары гына калды.
– Да-а... Барысы да җыр телиләр, диген... Исемнәренә күрә түгел... Әйдә ярар, Матак икән Матак инде. Нәби Дәүли шаккатсын әле. Ярты сәгатьтән шылтыратып текстны әйтермен, көен яза тор.

Һәм Шагыйрь рифмалар сайларга керешә. Кушымтадан башлады ул, эш стиле шундый аның:

Әй, Базарлы Матагым,
Сиңа ни кирәк тагын?
Яки:
Әй, Базарлы Матагым,
Сагынам алма ботагын...
Юк:
Әй, Базарлы Матак та,
Төшкә керсен кайчакта...
Бәлки:
Әй, Матакның Базарын,
Сөям сөтен-мазарын...
Әгәр:
Ай-ли, матаклылар,
Һәр эштә атаклылар...
Әллә:
Без планнарны үтәрбез,
Кирәксә өч йөз итеп.
Ай-ли, Матаклы,
Елашмагыз шул чаклы?...
Юк. Болай. Тегеләй. Хәзер...

...Җыр язылып беткән дип ишеттек. Базарлы Матак кешеләре концерт яңгыраган саен, безнең авыл көен җырламасалар ярар иде дип, радионы борып-ябып куялар ди...

...Ә «Прогресс» нәшрияты авторның унбиш томлык сайланмаган әсәрләренә өстәр өчен «Базарлы Матак» җырын түземсезләнеп көтә иде инде.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1980.)

Мәзәкият

ЫСУЛ

Мәҗнүн премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ трамвайда булсын, театрда булсын – берәр сылу кыз күрсә, болай дип сүз ката икән:

– Туташ, сез французча беләсезме?

– Юк, абый, белмибез, – дисәләр, Рәдиф:

– Кызганыч, юкса рәхәтләнеп бер сөйләшкән булыр идек! – ди.

Бервакыт шулай дип эндәшкәч, таныш түгел гүзәл французча сөйләшә башлый. Рәдиф каушап кала һәм:

– Кызганыч, мин дә французча белсәм, рәхәтләнеп бер сөйләшкән булыр идек! – дип, кыз янынан нәүмиз генә китеп бара.

(Батулланың «Тузга язмаган хәлләр» дигән китабыннан алынды.)

Кызыклы ракурс

Л. ЛЕРОН фотосы

Рәсемдә (сулдан уңга): Вакыйф Нуриев, Зиннур Мансуров һәм Хатип Миңнегулов. 2012.

ИКЕ РОБАГЫЙ

Ләбиб ЛЕРОН

Көндәшен ул чоеп атты баш аркылы...
Чү! Нәрсә бу, и инәнне корт чаккыры?!
Җилкәсенә тәкә... дисәм... чучка салып...
Кайтып килә сабантуйның баш батыры.

Сәхнә тулды яулык чөйгән ирләр белән,
Колак тонды шырдый-бырдый җырлар белән.
Бетсә бетсен татар җыры, юморы, дип...
Сәхнәләргә мин дә чыгып мырлар булам.

ЭКСПРОМТ

Факил САФИН

Җидегә бөкләнеп,
унга төрләнеп,
Ил ята буылып ютәлөнә...
Күршеләрнең
мүкләк кәҗәләре
Хуҗа булган
шалкан түтәленә...



Сүзсез

Ф. МУЛЛАХМӘТ рәсеме

Сәхифәне Ләбиб ЛЕРОН әзерләде

Әйтер сүзем бар

Берара кино-театр эше җиргә йөри алмый башладым. Карарлык фильм-спектакльләр юклыктан да, вакыт булмаудан да, хәтта акча җәлләүдән дә түгел. Заманадан артта калып бару сәбәпле, ахры, халык арасында үземне ничек тотарга белмәүдән.

Нәрсәдән көләбез, җәмәгать?!

Фәнзилә МОСТАФИНА

Мондый тамашалардан, тәгәрләп итеп әйтсәк, тамаша кылучылардан күңелем кайту быелгы Халыкара Казан мөселман киносы фестиваленнән башланды бугай. Халыкның үз-үзен тотышы кысаларга сыешмавы белән аңарчы да очрашкан бар иде, әлбәттә. Тик фестивальдә бер атна «яшәп», гади караучы гына түгел, чараны яктыртучы буларак та күзәтә торгач, гаҗәпләнүем касәсеннән ташып чыкты. Ике тиенлек сүз сөйләп, күңелне күрә торган тапшыру-чараларга шул хәтле күнеккәнбез ки, затлы-зыялы тамашаларда да шул гадәтләребездән арына алмыйбыз. Фильм яки спектакль вакытында кәрәзле телефонны сүндереп кую турында әйтмим дә инде мин. Күпме генә кисәтсәләр дә, барыбер бер-ике «акыллысы» табыла. Иң кызыклы урында чәрелдәп телефон кычкыра башлый. Әле шул «акыллыбаш»ның берсе булса да, бөтен залны яңгыратып, шалтыратучыга кайда, ничек, нәрсә эшләп утыруы турында хисап бирми калмый.

Телефон мәсьәләсендә күптән өметсезлеккә бирелеп, кул селтәдем инде мин. Дәртләнеп-канатланып мәхәббәт аңлату күренешен уйнап ятканда кинәт телефон чәрелдәвенә артистлар да ияләшкәндер. Халыкның мондый тамашаларга аңлы рәвештә йөриме-юкмы икәнен генә беләсем килә.

Мондый сорауны бирерлек сәбәпләр бар. Ничек кенә тырышсам да, тиешле-тиешсез урында залны яңгыратып көлеп җибәргән, сәхнәдә яки экранда барган күренешкә бармак төртеп, комментарий сиптерә башлаган кешене аңлап бетерә алмыйм. Төшләнеп китеп көләдер, дисәң, юк, тамашадан көлә. Кызыктан авыз ерса бер хәл, кычкырып елаулык урында шаркылдый. Мине юморны аңламауда гаепләр идең, бер-ике «искәрмә»дән кала, аңлы тамашачы җитди утыра. Менә шул хәлнең хикмәтен һич төшенә алмый интегәм.

Мөселман кинофестивалендә катнашкан картиналарны караучылар арасында чит ил вәкилләре дә бар иде. Юри шуларны күзәтеп утырдым, безнекеләр болай да үзләренең барлыкларын онытырга ирек бирмәде. Фильм эченә чумып кына китәсең, безнекеләр утырган кәнәфи турысыннан шаркылдап көлгән тавыш ишетелә. Әллә мин генә аңышмый калдыммы икән, дип, калганнарга карыйм. Юк, чит ил кунаклары көлми. Экранга текәлеп, көләрлек әкәмәт эзлим: туганнар очрашу хөрмәтенә хәмер эчәләр; туйда ду кубып биеп йөргәндә, берәүне йөрәк өянәге аяктан ега; солдатлар бернәрсәсез калдырган чечен карты иске машинаны этеп, өенә алып кайта... Юк, көләрлек берни дә юк бит. Режиссерның фикерен аңлаучыны уйландырырлык күренешләр ләбаса.

Мондый тамашаларга бүтән бармыйм, дип кайтам да, күңел рухи байлыкка сусагач, тагын чыгып китәм. Күптән түгел Тинчурин театрында кызык та, кызганыч та хәл булды. «Төш» спектаклендә чәчәк кебек хатын, тормыш баткаклыгына каршы тора алмыйча, сектага килеп эләгә, ире өйдә бикләп калдыра башлагач, хәмергә ябыша, ахырда, бөтенләй сукбай дәрәҗәсенә төшә. Пьесаның авторы Туфан Миңнуллин белән режиссер Рәшит Заһидуллин сәләмә киемнәргә төренгән, кеше дип атарлыгы да калмаган хатынны тамашачының ничек кабул итүен теләгәннәрдер, тәгәл әйтүе кыен, тик мин барган көнне зал сукбайны шаркылдап каршылады. Тормыш иптәшенең дә, үзенең дә көчсезлеген таныган ир хатынының яңагына суккач, бөтен зал аһ итәргә тиеш кебек иде. Тагын алдандым – халыкның көләсе килү теләге көчлерәк булып чыкты. Иң гаҗәпләндергәне: бөтен зал «купты». Борчу-мәшәкатьләр бар, дип, һаман елап йөрәп булмаганга көлү дип аңласаң гына инде моны. Башкача кабул итә алмыйм.

Кайда син, «Татар иле»?

Узган атнада Бөтендөнья татар конгрессына, «Татар иле» проекты тирәсендә купкан зур шау-шу уңаеннан, Кремльнең Хисап палатасыннан тикшерү килде.

Корылтай узгач, хакимияттән зур акчалар бүленеп тә, әлеге проектның эшләнеп бетмәгәнлеге, хәтта концепциясе дә әле яңа тәгаенләнә башлаганлыгы ачыкланды. Ни-нәрсәләр эшләнергә тиешлеген секция утырышында гәпләшеп, бурычларны билгеләп, корылтай ахырында резолюциягә керттеләр. Корылтай узгач, Бөтендөнья Татар яшьләре форумы рәисе һәм әлеге порталның директоры булган Тәбриз Яруллин: «Татар иле» баткаклыгыннан китәм», – дип белдерде. Нәтиҗәдә вазифалар Тәбриз Яруллинга йөкләнгәнче, «Татар иле» проектының авторы булып торган «Белем ру» оешмасының хуҗасы, миңа «Татар иле»нең финанс өлеше белән идарә итәргә ирек бирмәделәр» дип белдерүче Раил Гатауллин үз урынына кире кайтарылды.

Ә бит «Татар иле» порталы проекты корылтайның төп күчтәнәчене, Бөтендөнья татар конгрессының соңгы елларда башкарган иң зур, иң уңышлы эшләренең берсенә әверелергә тиеш иде. Аның ачылу тантанасы бер ел кичектерелеп киленде. Корылтай вакытында исә делегатларга слайдшоу рәвешендә порталның яңа күзаллана башлаган планы гына күрсәтелде. Кыскасы, бу эш барып чыкмады.

Корылтайдан соң бу хакта интернеттагы кайбер матбугат чаралары язмалар бастырды, ә 19 декабрьдә Рөстәм Хәйруллин (@amckhayr) исемле егет Рөстәм Миңнехановның «Twitter»дагы микроблогына «Татар иле» чентәренә бүленгән акчаның Конгресс тарафыннан ничек тотылганын тикшерүегезне сорыйм. БТК проектка комачаулый гына» дигән эчтәлекле хат юллаган иде.

Нәтиҗәдә ТР Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарә җитәкчесе Марс Баһаветдинов төзегән махсус эксперт комиссиясенең тикшерү нәтиҗәләре түбәндәгечә. «Татар иле» социаль челтәре өчен ТР Мәдәният министрлыгыннан 15 миллион сумга якын акча күчерелә (14.8 млн). Бирелгән акчаның 7 миллионга якыны тузды-рылган, ә тиеш эш өчен тотылган сумма 5,7 миллион сумны тәшкил итә. «Әлегәчә «Татар иле» бары тик мәгълүмат порталы гына булып кала бирә. 12 бүлекнең нибары 5есе генә эшли», – диелә комиссиянең хисабында.

БАЙЛАР да елый

Руслан – тормыш иптәшемнең якын дусты. Кечкенәдән үк бергә аралашып үскәннәр. Житеш, мул тормышлы гаиләдән. Заманында әтисе шактый танылган прокурор булган, әмма шаушулы 90 нчы елларда аны үтергәннәр. Ирен югалткач, әнисе Анна Аделевна башкага кияүгә чыкмаган, бердәнбер улын ялгызы тәрбияләгән.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Улын җил-яңгыр тидертми үстергән, югары белемен дә биргән, башкаланың иң яхшы рестораннарының берсендә купшы туй ясаган. Кыскасы, Руслан акчага кытлык кичереп үскән дип әйтеп булмый. Әмма аңа карап ул бервакытта да борын чөеп сөйләшмәс, акчаның кадерен белә торган ир-ат. Моның өстенә, җаваплы, төгәл һәм ярдәмчел кеше булуын да өстәсәң, хөрмәткә лаек сыйфатлары шактый җыела. Тормыш юлын бергә үтәргә сайлаган ачык йөзле, аралашучан сөйгән яры белән дә уртак телне тиз таптык. Әмма ни дисәң дә, безнең кебек авыл кызларыннан аерыла инде.

Руслан, дүрт бүлмәле фатирда әнисен ялгызы калдырырга теләмәде, шуңа күрә туйдан соң яшьләр бергә яши башладылар. Әдиләл исемле кызлары да туды. Тик менә Анна Аделевнаның сеңлесенә уңышсыз операция ясалды һәм нәтиҗәдә аның аяклары йөрмәс булды. Хәзер ул ханым да Русланнар белән бергә яши, Анна Аделевна да вакытлыча эштән чыгарга мәҗбүр булды.

Тормыш мәшәкатьләренә чумып, дусларыбыз белән күптән очрашкан юк иде. Яңа ел бәйрәмнәрендә үзләренә кунакка чакырдылар. Табын артында сөйләшеп утыргач, хуҗабикә белән чәй алып керергә дип кухняга чыктык.

– Туйдым инде бергә яшәп, – диде Алена кинәт кенә. – Көн саен Русланга, үзебезгә фатир алыйк та аерым яшик, дип әйтәм. Мин үземне каенанага кияүгә чыккан кебек хис итәм. Руслан эштә, без Анна Аделевна белән көне буе бергә. Бер-беребездән арыганбыздадыр инде. Җитмәсә, ул салкын тидереп еш авырый. Аны да, баланы, авыру сеңлесен карау да минем җилкәгә төшә. Ипотекага басып, аны гомер буе түлисе дә килми. Әни бер айдан эшкә чыгарга тиеш тә, тик аның авыру сеңлесен кем карар икән инде?

Әллә нишләп киттем шунда. И, мәйтәм, сезгә дә акча җитмәгәч инде. Бар булганына шөкрана кылып, сабыр итәргә өйрәнсәк иде без. Ә тормышлары шөкер итмәслек түгел. Аллага шөкер, үзләре дә, балалары да сау-сәламәт. Руслан яхшы эштә эшли. Туйдан соң ук фатирларына менә дигән итеп ремонт ясадылар, бар иске җиһазлар урынына яңаларын кайтарып тутырдылар, шәп машина сатып алдылар. Алена бәби алып кайтканчы бер генә көн дә эшкә чыкмады. Аңа да карамастан, танышлары аркылы документлар ясатып, декрет акчасын бездән күбрәк алды. Хәзер дә миннән ике тапкыр артыграк пособие килеп тора. Бала өчен кирәк-яраклар да иң яхшылары гына. Шуңа дә канәгать булмасаң инде.

Шөкер итә белү-белмәү дигәндә, күңелемдә гел бер вакыйга яңара да, ирен читенә елмаю менеп кунаклый минем. Баламны табибларга акча түләмичә генә табам, иң мөһиме Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын, дип карар иткән идем. Аллага шөкер, тулгак ачысын кичереп, сау-сәламәт нарасыемны күкрәгемә кысып сөяргә насыйп булды. Ул вакытларда берничә хастаханәдә ремонт эшләре бару сәбәпле, 1 нче балалар тудыру йорты шыгрым тулы иде. Яңа гына бәби алып кайткан хатын-кызларның барысына да палатада урыннар җиткерә алмыйлар. Кичкә кадәр коридордагы ятакларда яткырлар да, урын бушагач, палатага күчерәләр. Минем белән дә шулай булды. Яңашәмдәге ятакка тагын бер яшь әнине китереп салдылар. «Ни пычагыма 15 мең сум акча түләдем соң мин? Шушы коридорда ятар өченме? Баланы да авырлык белән таптым. 12 сәгать чирләдем. Ятып та, басып та торып булмый җитмәсә», – диде бу, бераз хәл җыйгач.

Кичен безне дә палатага күчерделәр. Тегө коридордан соң рәхәт инде, сумкаларыбызны бушатып, хастаханә өчен кирәк-яракларны урнаштырып та куйдык. Тиздән баламны имезергә алып киләчәкләр. Ниһаять, рәхәтләнеп күзләренә бага, күкрәгемә кочა алачакмын. Сүз белән аңлатып бетерә алмаслык әнә шул татлы мизгелне көтеп, йөрәк чиктегеннән сикереп чыгардай булып тибә. Башка вак-төяк мәшәкатьләр, авыртулар турында уйлыйсы да килми. Ә палатада яткан берничә хатынның башы зарланудан чыкмый. «Мин бу бала тудыру йортын бик яхшыдыр дигән идем. Ә монда заманча ремонтлары да ясалмаган, стеналары да буялмаган, башка уңайлы шартлар да юк. Танышларыма монда килмәскә кушам». Бар сөйләгән сүзләре шул. Журналист практикасында күргән шактый медицина һәм социаль яклау учреждениеләре белән чагыштырганда, 1 нче балалар тудыру йортын начар дип әйтеп булмый югыйсә. Димәк, нинди очракка ничек карыйсың инде. Аннан соң кем нәрсәдән тәм таба бит. Балдамайда йөзеп, һаман акча юк дип зарланып яшәүдәнме, әллә бар булганына риза булып шөкер итә белүдәнме.

ДҮШӘМБЕ
28 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ДВЕ СЕСТРЫ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00, 02.00 «Җырлыйк әле!» (6+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
13.00 «Семь дней». (12+)
14.00, 18.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Реквизиты былой суеты» (12+)
14.35 «Быть свободным легко». Премьера телефильма (12+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Тамчы-шоу» (6+)
16.00 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 21.30 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак Барс» (Казань) – «Барыс» (Астана). Трансляция из Казани (12+)
21.15 «Бизнес Татарстана» (12+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
11.30 «Парламентские вести»
14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать»
15.50 «Ты не один» (16+)
16.20 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
17.00 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ» (12+)
23.25 «Вечерний Ургант» (S) (16+)
00.00 «Свобода и справедливость» с Андреем Макаровым (18+)
01.00 Ночные новости
01.20, 03.05 Х/ф «ОХОТНИКИ ЗА ПРИВИДЕНИЯМИ» (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Россия
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-11». (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 Т/с «РУССКАЯ СЕРИЯ». «ГРОМ»
23.15 Премьера. «Болезни века. Кто кого?» (12+)

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.05 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Живут же люди!» (0+)
10.55 «До суда» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Х/ф «ПЕТРОВИЧ» (16+)
21.30 Т/с «ОДИНОКИЙ ВОЛК» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Х/ф «БРИГАДА» (18+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Лучшие воинские части» (16+)
06.10 Итоги недели
07.00 Т/с «СИЛЬНЕЕ ОГНЯ» (16+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 Новости
09.25 Х/ф «НЕСЛУЖЕБНОЕ ЗАДАНИЕ» (16+)
11.20 Х/ф «ВЗРЫВ НА РАССВЕТЕ» (16+)
13.15 Д/с «Отечественное стрелковое оружие». «Бесшумное и специальное оружие» (12+)
14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
14.15, 16.15 Т/с «КАПКАН» (16+)
17.15 Д/с «Легенды советского сыска». «Перелет ценою в жизнь» (16+)
18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
19.30 Т/с «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-4» (16+)
22.30 Т/с «ПРОТИВОСТОЯНИЕ» (12+)
23.45 Х/ф «ТАЙНАЯ ПРОГУЛКА» (12+)

КУЛЬТУРА
07.00 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 01.40 Т/с «ПЕРРИ МЭЙСОН»
12.10 «Охота на Льва». Авторская программа Льва Аннинского. 1 серия (*)
12.40 Д/ф «Восхождение»
13.20 Д/ф «Небесный танец Бутана»
14.15 «Линия жизни». Елена Шанина. (*)
15.10 «Пешком...» Москва узорчатая
15.40, 19.30, 23.30 Новости культуры
15.50 Спектакль «ЧУДАКИ»
17.15 «Звезды мировой оперной сцены». Дмитрий Хворостовский
18.10 Важные вещи. «Духовный регламент»
18.25 Д/с «Географические открытия»
19.45 Главная роль
20.05 «Сати. Нескучная классика...» с Василием Бархатовым и Феликсом Коробовым
20.45 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №13
21.30 «Острова»
22.15 «Тем временем»
23.00 Д/с «Мира. Дочь командарма Уборевича»
23.55 Документальная камера. «Кино и театр. Новая степень правды, или Возрождение антрепризы»
00.35 «Кинескоп» с Петром Шепотинником

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00, 13.00 «Званый ужин» (16+)
10.00 Х/ф «СМЕРТИ ВОПРЕКИ»
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00 «Не ври мне!» (16+)
17.00, 18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 «Военная тайна с Игорем Прокопенко» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)
23.50 Х/ф «СНАЙПЕР»
01.50 Т/с «СВЕРХЪЕСТЕСТВЕННОЕ»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Скуби Ду. Корпорация «Тайна»
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00, 13.00, 00.00 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
09.00, 09.30, 13.30, 18.15, 01.30 Т/с «6 кадров» (16+)
10.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 М/ф «Ролли и Эльф. Невероятные приключения» 2007 г.
14.00 Х/ф «КОВБОИ ПРОТИВ ПРИШЕЛЬЦЕВ» (16+)
16.15 М/ф «Ранго» (12+)
19.00 «КУХНЯ» (16+)
20.00 «ВОСЬМИДЕСЯТЫЕ» (16+)
21.00 «МЕТОД ЛАВРОВОЙ» (16+)
22.00 Х/ф «БОЛЬШОЙ СТЭН» (16+)

СПОРТ
05.00, 07.45 «Все включено» (16+)
05.50, 03.50 «Моя планета»
06.35 «В мире животных» с Николаем Дроздовым
07.05, 09.00, 11.25, 16.45 Вести-спорт
07.15 «Моя рыбалка»
08.40, 11.05, 03.35 Вести.ru
09.10 Х/ф «НАПРОЛОМ» (16+)
11.55 Хоккей. КХЛ. «Амур» (Хабаровск) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
14.15 Конькобежный спорт. Чемпионат мира в спринтерском многоборье. Трансляция из США
15.00 Профессиональный бокс
16.55 Х/ф «ИДУЩИЙ В ОГНЕ» (16+)
18.55 Футбол. Международный турнир Copa del Sol. ЦСКА (Россия) – «Стремсгодсет» (Норвегия). Прямая трансляция из Испании
20.55 Х/ф «ГОСПОДА ОФИЦЕРЫ. СПАСТИ ИМПЕРАТОРА» (16+)
22.55 Неделя спорта
23.50 «Суперлайнер: инструкция по сборке»»

СИШӘМБЕ
29 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Аулак өй» (6+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» 0+
15.15, 21.00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
16.00 «TAT-music» (12+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
19.00 Д/ф «Меркурий и Венера». «Вселенная» (12+)
20.30 «Татар халык җырлары» (0+)
22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)
00.00 «Автомобиль» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Мир культуры»
09.20 Д/ф «Волжская рокада»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать»
15.50 «Ты не один» (16+)
16.20 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
17.00 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ» (12+)
23.25 «Вечерний Ургант» (S) (16+)
00.00 Ночные новости «Городские пижоны»
00.20 «Задиры». Новый сезон (S) (16+)
01.30, 03.05 Х/ф «ОХОТНИКИ ЗА ПРИВИДЕНИЯМИ 2» (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Россия
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45, 04.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-11». (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 Т/с «РУССКАЯ СЕРИЯ». «ГРОМ»
23.25 Специальный корреспондент. (16+)
00.30 Премьера. «Кузькина мать. Итоги». «Мертвая дорога». (12+)
01.25 Вести +
01.45 «Честный детектив». Авторская программа Эдуарда Петрова. (16+)

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.05 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Поедем, поедим!» (0+)
10.55 «До суда» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Х/ф «ПЕТРОВИЧ» (16+)
21.30 Т/с «ОДИНОКИЙ ВОЛК» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Х/ф «БРИГАДА» (18+)
00.35 Т/с «ДЕМОНЫ» (16+)
01.40 Главная дорога (16+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Дороже золота» (16+)
06.20, 18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
06.30, 14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
07.00 Т/с «СИЛЬНЕЕ ОГНЯ» (16+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 Новости
09.15 Х/ф «ВТОРЖЕНИЕ» (12+)
11.00, 19.30 Т/с «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-4» (16+)
13.15 Д/с «Отечественное стрелковое оружие». «Снайперское оружие» (12+)
14.15, 16.15, 03.10 Т/с «КАПКАН» (16+)
17.15 Д/с «Легенды советского сыска». «Фантомасы против МУРа» (16+)
22.30 Т/с «ПРОТИВОСТОЯНИЕ» (12+)
00.45 Х/ф «ПОКА ФРОНТ В ОБОРОНЕ» (12+)
02.25 Д/с «Легенды советского сыска». «Перелет ценою в жизнь» (16+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 01.55 Т/с «ПЕРРИ МЭЙСОН»
12.10 «Охота на Льва». Авторская программа Льва Аннинского. 2 серия (*)
12.40 «Острова»
13.25, 18.25 Д/с «Географические открытия»
14.25 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №9
15.10 «Пятое измерение». Авторская программа И. Антоновой. (*)
15.40, 19.30, 23.30 Новости культуры
15.50 Спектакль «ЧУДАКИ»
16.55 Д/ф «Мировые сокровища культуры».
17.15 «Звезды мировой оперной сцены». Брин Терфел
19.45 Главная роль
20.05 Власть факта. «Человек и война»
20.45 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №14
21.30 «Больше, чем любовь»
22.15 «Игра в бисер» с Игорем Волгиным. «Уильям Фолкнер. «Шум и ярость»
23.00 Д/с «Мира. Дочь командарма Уборевича»
23.55 Х/ф «МОЛЧАНИЕ ЖАННЫ»
01.20 «Фантазия по-американски для двух роялей».

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00, 13.00 «Званый ужин» (16+)
10.00 «Следаки» (16+)
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00 «Не ври мне!» (16+)
17.00, 18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 ПРЕМЬЕРА. «Территория заблуждений с Игорем Прокопенко» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)
23.50, 02.45 Х/ф «НАПАДЕНИЕ НА 13-Й УЧАСТОК»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Скуби Ду. Корпорация «Тайна»
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00, 11.00, 13.00, 00.00 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
09.00, 13.30, 23.40 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
09.30, 21.00 «МЕТОД ЛАВРОВОЙ» (16+)
10.30, 18.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 М/ф «Паутина Шарлотты-2. Невероятное приключение Уилбера» 2003 г.
14.00 Х/ф «БОЛЬШЕ ЧЕМ ДРУГ» (16+)
16.00 М/ф «Сказки Шрэкова болота»
17.30, 20.00 «ВОСЬМИДЕСЯТЫЕ» (16+)
19.00 «КУХНЯ» (16+)
22.00 Х/ф «МУЖЧИНА ПО ВЫЗОВУ» (16+)
00.30 Х/ф «БАЗА» (18+)
02.20 Х/ф «ЗАБЫТОЕ» (16+)
04.05 Т/с «ТАКАЯ РАЗНАЯ ТАРА»
05.10 М/ф «Хочу бодаться!» (0+) «Три дровосека»

СПОРТ
05.00, 07.45 «Все включено» (16+)
05.50 «Вопрос времени». Поработители
06.20, 02.45 «Моя планета»
07.05, 09.00, 11.45, 22.55 Вести-спорт
07.15 «Диалоги о рыбалке»
08.40, 11.25, 01.40 Вести.ru
09.10 Х/ф «ЧЕРНЫЙ ГРОМ» (16+)
10.55 «Наука 2.0. Опыты дилетанта». Пожарный на линии огня
11.55 «Братство кольца»
12.25 Х/ф «ГОСПОДА ОФИЦЕРЫ. СПАСТИ ИМПЕРАТОРА» (16+)
14.30 Х/ф «СПЕЦНАЗ»
15.30 «Наука 2.0. ЕХперименты». Бронежилет в домашних условиях
16.00 «Наука 2.0. ЕХперименты». В яблочко!
16.30 «Наука 2.0. ЕХперименты». На острие
17.00 Х/ф «УЛЬТРАФИОЛЕТ» (16+)
18.45 Х/ф «ОБИТЕЛЬ ЗЛА» (16+)
20.40 Х/ф «ОБИТЕЛЬ ЗЛА-2» (16+)
22.25 «IДетектив» (16+)
23.10 «Планета футбола» Владимира Стогниенко
23.40 Футбол. Чемпионат Англии. «Куинз Парк Рейнджерс» – «Манчестер Сити». Прямая трансляция

ЧӘРШӘМБЕ
30 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ДВЕ СЕСТРЫ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00 «Татар халык җырлары» (0+)
11.30 «Халкым минем...» (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
13.00 «Секреты татарской кухни» (12+)
13.30 «Среда обитания» (12+)
14.00, 18.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Актуальный ислам» (6+)
14.25 «Нәсыйхәт» (6+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.15 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Без – Тукай оныклары» (6+)
15.45 «Һөнәр» (6+)
16.00 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 21.30 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак Барс» (Казань) – «Югра» (Ханты-Мансийск). Трансляция из Казани (12+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать»
15.50 «Ты не один» (16+)
16.20 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
17.00 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ» (12+)
23.25 «Вечерний Ургант» (S) (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Россия
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-11». (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 Т/с «РУССКАЯ СЕРИЯ». «ГРОМ»
23.25 Х/ф «ПЛАНЕТА ВАВИЛОН. ХРОНИКИ ВЕЛИКОЙ РЕЦЕССИИ» (16+)

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.05 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Чудо техники» с Сергеем Малозёмовым (12+)
10.55 «До суда» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Х/ф «ПЕТРОВИЧ» (16+)
21.30 Т/с «ОДИНОКИЙ ВОЛК» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Х/ф «БРИГАДА» (18+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Дороже золота» (16+)
06.20, 18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
06.30, 14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
07.00 Д/с «Отечественное стрелковое оружие». «Бесшумное и специальное оружие» (12+)
07.45, 22.30 Т/с «ПРОТИВОСТОЯНИЕ» (12+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 Новости
09.15 Т/с «ПРОТИВОСТОЯНИЕ»
10.20 «Сильная Россия. Энергетический прорыв» (12+)
11.00, 19.30 Т/с «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-4» (16+)
13.15 Д/с «Отечественное стрелковое оружие». «Пистолеты» (12+)
14.15, 16.15, 03.10 Т/с «КАПКАН» (16+)
17.15 Д/с «Легенды советского сыска». «Советский Робин Гуд» (16+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 01.55 Т/с «ПЕРРИ МЭЙСОН»
12.10 «Охота на Льва». Авторская программа Льва Аннинского. 3 серия (*)
12.40 «Больше, чем любовь»
13.25, 18.25 Д/с «Географические открытия»
14.25 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №10
15.10 Красуйся, град Петров! Зодчий Гаральд Боссе. (*)
15.40, 19.30, 23.30 Новости культуры
15.50 Спектакль «ВИШНЕВЫЙ САД»
17.15 «Звезды мировой оперной сцены». Василий Ладюк и Дмитрий Корчак
18.05 Важные вещи. «Бюст Победоносцева»
19.45 Главная роль
20.05 «Абсолютный слух».
20.45 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №15
21.30 Д/ф «Леонид Гайдай... и немного о «бриллиантах»
22.15 Магия кино. Ведущие М. Борзенков и О. Шишкин
23.00 Д/с «Мира. Дочь командарма Уборевича»
23.55 Х/ф «КАРМЕН»

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00, 13.00 «Званый ужин» (16+)
10.00 «Следаки» (16+)
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00 «Не ври мне!» (16+)
17.00, 18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 ПРЕМЬЕРА. «Нам и не снилось»: «Темная магия золота» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)
23.50, 03.00 Х/ф «ЧЕЛОВЕК-ВОЛК»
02.10 Т/с «СВЕРХЪЕСТЕСТВЕННОЕ»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Скуби Ду. Корпорация «Тайна»
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00, 13.00, 00.00 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
09.00, 13.30, 15.50 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
09.30, 21.00 «МЕТОД ЛАВРОВОЙ» (16+)
10.30, 18.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 М/ф «Сказки Шрэкова болота»
14.00 Х/ф «ЛЮБОВЬ И ПРОЧИЕ НЕПРИЯТНОСТИ» (16+)
16.00 М/ф «Кунг-фу Панда. Невероятные истории»
17.30, 20.00 «ВОСЬМИДЕСЯТЫЕ» (16+)
19.00 «КУХНЯ» (16+)
22.00 Х/ф «ПОМЕНЯТЬСЯ МЕСТАМИ» (16+)
00.30 Х/ф «НИЧЕГО НЕ ВИЖУ, НИЧЕГО НЕ СЛЫШУ» (16+)
02.30 Х/ф «911. МАЛЬЧИКИ ПО ВЫЗОВУ» (16+)

СПОРТ
05.00, 07.45 «Все включено» (16+)
05.50 «Суперлайнер: инструкция по сборке»
07.05, 09.00, 11.35, 22.55 Вести-спорт
07.15 «Язь против еды»
08.40, 11.15, 01.40 Вести.ru
09.10 Х/ф «КАРТЫ, ДЕНЬГИ И ДВА СТВОЛА» (16+)
11.45 Горнолыжный спорт. Кубок мира. Трансляция из Москвы
12.45 Х/ф «ОБИТЕЛЬ ЗЛА» (16+)
14.40 Х/ф «ОБИТЕЛЬ ЗЛА-2» (16+)
16.25 «Основной состав»
16.55 Хоккей. КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) - «Авангард» (Омская область). Прямая трансляция
19.15 Х/ф «ОХОТНИКИ ЗА КАРАВАНАМИ» (16+)
22.25 «Полигон»
23.10 «Планета футбола» Владимира Стогниенко
23.40 Футбол. Чемпионат Англии. «Арсенал» – «Ливерпуль». Прямая трансляция

ПӘНҖЕШӘМБЕ
31 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ДВЕ СЕСТРЫ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00 «Кара-каршы» (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
13.00 Телефильмы «Василий Аксёнев. Казань. Автограф на Юности», «Адель Кутуй. Письма в будущее», «Остров памяти. Шариф Камал» (12+)
14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана (12+)
14.15, 00.00 «Волейбол». Тележурнал (12+)
14.45 «Путь» (12+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Мәктәп» (6+)
15.45 «Көлдермеш» (6+)
16.00 «TAT-music» (12+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 «В мире культуры» (12+)
20.30 «Татарлар» (12+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)
02.00 «Ак юл сиңа!» Айрат Имашев (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Музыкальная жизнь»
09.20 «Дорога к дому»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

